**Мөслимова Фәйрүзә**

# Апрель кары

Шигырьләр

Казан
Татарстан китап  нәшрияты
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84(2Рос = Тат)-5
М 78

**Мөслимова Фәйрүзә**

Апрель кары: Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 176 бит.

Фәйрүзә Мөслимова шигырьләре ихласлыгы, самимилеге белән күңелне үзенә тарта. Аларда — туган җиргә, илгә, кешегә мәхәббәт. Шигырьләр шагыйрә күңелендәге тирән сагыш, моң белән өртелгән.

ISBN 5–298–01405–4
© Татарстан китап нәшрияты, 2004

## Талпынудан туган агым

Фәйрүзә Мөслимова данлыклы җырчылар биргән Актаныш туфрагыннан. Мәшһүр җырчыбыз Әлфия Афзалова исемен атау гына да моңа тиешле дәлил була ала. Агыйдел буйларыннан килгән һәр икенең берсе җырчы, һәр икенең берсе шигырьче. Нәкъ менә Фәйрүзә Мөслимова «бу якларда һәр икенең берсе шигырь яза» дигән сүзне бар дөньясына кычкырып әйтте дә шул. Әгәр һәр икенең берсе шигырь яза икән, мондый бәягә лаек төбәкнең яшәү рәвеше белән чын-чынлап кызыксынырга, мондый могҗизаның сәбәпләрен белергә тырышырга кирәктер.

Безнең Яңаул төбәгендә бик тә ихлас, табигый кешеләргә карата «бетерепләр дә Актаныш инде» дигән сүзләрне ычкындыралар. Мин, тимер юллы, зур вокзаллы, җирен җиде ят зимагур да таптаган район кешесе, Актанышларның рухи халәтендәге аерманы бик тиз тоеп өлгердем. Актаныш халкы озын-озак олы юллардан читтәрәк яшәве белән никадәр отканлыгын, бәлки, аңлап та өлгермәгәндер, әмма бәхет кайчак көтмәгән яктан да килә шул ул.

Әгәр дә Фәйрүзә Мөслимова атлы шагыйрәнең шигырьләрен укыганнан соң, сез Актанышка барып чыксагыз, ул шагыйрә бигрәк тә халыкчан, үз халкы теле белән сөйли икән дип таң калыр идегез. Аның шигырьләренә шул төбәк сөйләше, халык телендәге әйтем-гыйбарәләр шулкадәр табигый кереп китәләр ки, әйтерсең лә Агыйделгә нәни чишмәләр килеп кушыла. Өстәвенә алар Агыйделдәй җырлап та торалар, чөнки шагыйрә белә, җаннарга, күпчелек кешеләрнең җанына җыр белән керү җиңелрәк тә.

Фәйрүзә Мөслимова татар күңеленә нәкъ җыр белән килеп кергәндер дә әле. «Сыңар алка», «Яраттырасым килә» исемле шигырьләре шундый табигый агымлы булган өчен күренекле композиторларыбыз аларга көйләр язды һәм мәшһүр җырчыларыбыз аларны рәхәтләнеп халыкка җиткерделәр.

Ихласлык! Менә ул кеше күңелен шигъриятькә һәм үз шәхесенә тарта торган сыйфат. Дөньябыз сәерләнеп, җаннары яргаланып беткәч, сәнгать әһелләре арасында да икейөзле, «ике минле» яшәештә көн күрүчеләр күбәйде. Чөнки алар һәр аерымланган җан тармагын аерым-аерым булса да яшәтергә омтыла. Фәйрүзә алай итми. Ул җырда — бер, тормышта икенче түгел. Ул Кеше булып яшәүнең югары ноктасы тоемын югалтмаган. Ә мондый яшәеш исә шагыйрь өчен тамырларын җирдән аермый гына шигырьләрен күккә чөеп, үз җанын шул шигырьләре биеклегенә күтәреп яшәтә алудыр. Шуңа күрә аңа, шагыйрәнең үзенә, шигырьләре яшәү таянычыдыр.

Илем-көнем, уем-хыялларым
Мәшәкатьләр белән туп-тулы.
Таянычым булган шигырьләрдән
Көнләмәгез мине һич югы,—

ди шагыйрә «Һәр икенең берсе» исемле шигырендә. Үз язмышы яраланмаган шагыйрь башкалар язмышын да, шатлыкларның, очышның ни икәнен татымаган башкалар шатлыгын, бәхетен дә аңлый алмас иде. Фәйрүзә очуларның да, егылып төшүләрнең дә ни икәнен татыган зат. Үз җаны яралы булса да, башкаларның ярасын җыры белән ямарга омтыла, үз җанын башкаларга күпер итеп салган затны көчле рухлы дими, нинди дисең. Менә шушы сәләте аның янына күпләрне тарта да инде. Күп вакытлар мин аны кызу колашлы, салкын яңгырлы, кар-буранлы көннәрдә кешеләрне үз ышыгына сыйдыра алучы тирәк образында күрәм. Ул ташымый, тузынмый, әкрен генә җаннарга Агыйдел агымнарыдай агып кына керә. Аның туган җир җылысы салынмаган, мәхәббәттән, агымсулар моңыннан мәхрүм шигырьләре бөтенләй дә юк, ахры.

Агымсуга салыйк serebезне,
Бар дөньяга, әйдә, таратсын.
Ярын һичкем ятка калдырмасын,
Бары үзе генә яратсын,—

ди ул «Су буенда» шигырендә һәм бу юллар фәкать халык телендәге гыйбарәләрдән генә тора кебек.

Мин бу шигъри үрнәкләрне шагыйрәнең «Апрель кары» дип аталган җыентыгыннан алдым һәм бу китаптагы шигырьләрен шагыйрәнең шигъри осталыкка ирешүдә яңа баскычка күтәрелүе дип карыйм. Үкенечләр һәм чарасызлык тулы агым эченә шагыйрә инде саллы гына фәлсәфи фикерләрен сыйдыра. «Феникс», «Их, дөньясы», «Күчә комнар», «Мәңгелек өн» шигырьләре шул иҗади биеклектәге җимешләрдер.

Шагыйрьләребезнең күбесендә оя-гаилә темасы зур урын били. Фәйрүзә исә Кеше дигән затка җан җылысы да, тән җылысы да бирүнең иң табигый чарасы гаилә икәнлеген шигъри фәлсәфә аша әйтеп бирә. Чөнки дәүләтнең гаилә дигән нәни күзәнәкләрдән тукылганын кешелеккә кабат исбат итеп торасы юк. Шагыйрә шушы яклауга бик тә мохтаҗ оя, аның һәр баласы, һәр әгъзасы өчен:

Дулкын каккан, давыл кискән чакта
Бирешмәгән ныклы кыя бу,—

ди. Монысы белән инде, «Әйе, шулай булырга тиеш тә бит, тик инде ул ифрат кызу темплар белән җимерелеп бара шул»,— дип бәхәсләшергә була. Әмма хатын-кыз шагыйрь үзенә, анага яшәү суты бирергә тиешле гаилә җылысы җитмәүнең фаҗига икәнен шулай аңлатырга омтыла һәм... сак кына балалар җанына да шакый. Аның самими сафлык белән өртелгән бик тә гади шигырьләрен балалар рәхәтләнеп тыңлый. Әмма Фәйрүзә, Актаныш Фәйрүзәсе, гел дә шул Агыйделдәй табигый агышта. Әлегәчә балалар өчен бер генә китап та чыгармый, җаны кайчан «бала» дигән утрауга агып килеп туктаса, шул чакта гына аларның җаннарын ачып керермен дип яши, ахры. Әлегәчә балаларга бар әйтер сүзен «Сабантуй» гәзите һәм «Ялкын» журналы аша җиткерергә омтыла. Аның бу матбагаларга гомерлек тугрылыгы да, бәлки, шуның белән аңлатыладыр.

Фәйрүзәнең әйтер сүзе еш кына шигырь кысаларына сыймый, прозага — хикәяләргә күчә һәм бу жанрда да автор җаннарга керү алымнарын таба. Аның «Перә», «Гөлбүләк», «Башка кеше» исемле хикәяләре вакытлы матбугатта Агыйдел ярларына сыешмый болынга түгелгән күлләвекләрдәй генә күренеп калдылар. Хикәяләрендәге геройларның үзенчә-

лекләре шунда — алар шигъри җанлы, канатлы затлар. Тик очкан чакта канатлары киселеп, җиргә, аның да рухи тәмугына төшкәннәре һәм... анда да гөлләр үстерергә теләгәннәре. Шагыйрә, шул рәвешчә, җаннарны күкләргә күтәрә дә тагын җырга күчә. Аның шигырьләре теленең гадилеге, халык телендә гомер-гомергә яшәп килгән гыйбарәләрнең, борылмаларның табигый кереп урнашуы белән һаман көй сорап торалар сыман. «Юаныч», «Юкәле Кул», «Җәйге төн», «Кычыткан аралары», «Җәй кошы», «Йомгак», «Күбәләк» — тагы шундый дистәләгән шигырьләре җырга әверелер, үз көйләрен табар кебек.

Җырлап кына аккан су юлында киртәләр дә очрый бит. Фәйрүзәнең кайбер шигырьләре белән бәхәсләшеп аласы килгән чаклар да юк түгел. Әйтик, ул:

Димәк, таулар күчми калыр,
Шайтан килмәс иманга.
Шул килеш яшәрмен инде,
Үзгәрү юк миңа да,—

ди, үзенең «Үзгәрү юк» исемле шигырендә. Бу шигырьне укыганнан соң, минем:

Гел бертөрле тормам, тормам,—
Мин көн саен үсәрмен.
Әлегә мин фанилыкта,
Бакыена күчәрмен! —

дип кычкырасым килә. «Ялтырау», «Шигърият», «Сихерче», «Ни дияргә», «Җиде юл чатында» кебек шигырьләр дә шундыйлардан дияр идем мин. Әмма җыр, җанга җыр кирәк! Шагыйрә үзе дә туктаусыз җыр эзли. «Җыр эзлим» исемле шигырендә ул:

Җыр табып кайтам Себердән,
Җаным һаман җыр сорый, —

ди һәм «җыр» сүзенең шигырь мәгънәсендә генә түгеллеге аңлашыла да. Әле шуны да әйтәсем килә: Фәйрүзә Мөслимованың һәр шигыре талпыну, чарасызлыктан, гаҗизлектән, сагыш-моңнан талпыну һәм шул талпынудан туган агымга әверелгән. Әллә бу милләтебезнең дә халәте түгелме? Без һәммәбез җыр эзлибез, канатларыбызны чишәрлек Җыр!

Ишәл таулы, Шәбез сулы Актаныш җырчысының да шундый җырларын табасына өметем зур минем.

*Нәҗибә Сафина*

# Кар суында – ак каеннар...

## Яз

Ак каеннар яланаяк
Суга кереп басканнар...
Әллә инде кызлар сыман
Яратудан шашканнар?

Чайкыйлармы яулыкларын
Кар суларына салып?
Сихерләнеп калганнармы
Күл-көзгеләргә багып?

Үзләренең гүзәллеген
Беренче күргәннәрме?
Соклансыннар безгә, диеп,
Суларга кергәннәрме?

Кар суында ак каеннар...
Сөймәс җирдән сөярсең.
Кояш-егет көлә генә —
Тигез күрә һәммәсен.

## Өстенлектә

*(Шаяру)*

Борын-борын заманнардан
Килгән күркәм гадәтләр
Бүгенге көн кешесен дә
Өйрәтәдер әдәпкә.

Үткәннәрдән күчкән шулай
Хатын-кызга хөрмәт тә:
Ишек ачкач, безне алдан
Уздыралар, әлбәттә.

Тик борынгы заманнарда
Булмаган ишекләре.
Хәвеф-хәтәр саклап торган
Мәгарә тишекләрен.

Хәйләкәр булган бабайлар:
Һәр караңгы тишектән
Әбиләрне уздырганнар
Алдап-йолдап ничек тә.

Ә без бүген — күтәрелеп
Илаһи биеклеккә —
Сөенәбез үзебезнең
Бердәнбер «өстенлек»кә!

## Унҗидедә

Җиләк чәчәк аткан чаклар,
Йөрәккә ут капкан чаклар...
Саубуллаштык мәктәп белән —
Унҗиде яшь иде безгә!

Орлыкларны җил таратты,
Ел артыннан ел санатты...
Тик җыелсак бергә-бергә,
Унҗиде яшь һаман безгә!

Әле дә җиләк чәчәк ата,
Хуш исләрен җәй тарата.
Олыгаймыйк бер дә, бер дә.
Унҗиде яшь булсын безгә!

Яшьлегебез гөрләп торса,
Эшебездән дөнья уңса.
Без — сөенеч илгә-көнгә!
Унҗиде яшь чөнки безгә...

## Сак-Сок

Яшьлек дигән гөлбакчадан
Очып чыктык Сак-Сок сымак.
Без яраткан ал чәчәкләр
Башын иеп калды елап.

Кызарып таң аткан саен
Ерагайды арабыз да.
Шәфәкъ саен әрнү артты
Йөрәктәге ярабызда.

Кара-каршы очып киттек
Сагындырган тарафларга.
Шәфәкълардан күчкән моңнар
Көч өстәде канатларга.

Хыял белән янәшәдә
Өмет оча безнең сакта.
Чәчәк атып көтәрме соң
Яшьлек дигән ямьле бакча?

## Син — әкият

Мин сине уйлап чыгардым
Тик үзем өчен генә.
Ихлас белән ышандым да
Табындым исемеңә.

Мин сине уйлап чыгардым
Сине белмәгән килеш.
Әле һаман шул хыялдан
Башым әйләнеп йөреш.

Мин сине уйлап чыгардым,
Әкияткә буйсындым.
Кайчан күчте чынбарлыкка

Синең күзләр, буй-сының?

Буй җитмәслек рәшә булып
Ник төшемә керәсең?
Сүнеп барган учагыма
Тагын ялкын өрәсең?

## Дулкынланам?

Дулкынланам? Сиңа гына
Тоелгандыр шулай.
Тавышыңнан каушар өчен
Сәбәп тә юк болай.

Дулкынланам? Әйтер сүзем
Оныттырдың кебек.
Көтмәгәндә юлыкканга
Калдым, ахры, җебеп.

Дулкынланам? Менә кызык.
Идел кебек, имеш.
Язгы җилдән чайпалган чак
Инеш кенә килеш.

Синең тавыш — давыл кебек.
Чайпалмаска өйрәт.
Ахрысы, хак: Идел кебек
Дулкынландым кинәт.

## Үтенеч

Биектән карап сөйләшмә,
Күзләреңне күрмим.
Күздән башка аңлашу юк,
Аңлашмауны сөймим.

Биектән торып сөйләшмә —
Күзеңдәге серне
Күңелеңнең ераклыгы
Төшенергә бирми.

Ерактан торып сөйләшмә,
Зурлыгыңны тойыйм —
Күзләр, аваз, күңел аша
Барысын да сорыйм.

Барысы да тулы булсын,
Шул чагында сөйлә.
Бер-береңне аңламасаң,
Аралашу нигә?

## Сер

Без дөньяны куабызмы,
Әллә дөньямы — безне?
Йолдыз кебек үттең-киттең,
Камаштырдың да күзне.

Күкләремне нурга төргән
Йолдыз атылган минут.
Йөрәгемне ут итсә дә,
Калды җанда сер булып.

Үзем генә белгәнгәдер,
Бер ачы ул, бер татлы.
Газабым да шатлык кебек,
Шатлыгым да газаплы.

## Әллә ни булды миңа

Үзәкләрне өзә торган
Мондый сагыш, мондый моң
Көтмәгәндә каян килде,
Тетрәндереп, шундый соң?

Шомыртлар чәчәк атканда,
Әллә ни булды миңа:
Сыкранып, елап, сагынып
Тартылды күңел сиңа.

Еллар үткәч, язгы таңда,
Хыялда сиңа килдем.
Хисләрем калды җавапсыз,
Оялып башым идем.

## Пар чынаяк куйдым...

Кичә генә әле икәү идек...
Бүген менә...
тагын үзем генә.
Бер могҗиза булыр —
кайтыр, диеп,
Пар чынаяк куйдым өстәлемә.

Синең белән минем бәхет кенә
Хушлашудан, очрашудан тора.
Төшләреңә кереп йөдәтермен,
Син кайгырма —
сагына, дип юра.

Моңга чумган кичләр
шундый салкын!
Син булмагач, вакыт озак үтә.
Син кайт инде.
Очрашасы иде.
Мине дә бит яңа юллар көтә.

## Миләүшә

Әллә күңел — көмеш көзге?
Шул көзгедән төшмәде гел
Синең сурәт — миләүшә гөл —
Сеңелем төсле зәңгәр күзле.

Әллә күзләр, әллә сүзләр...
Охшаш икән кай ягыбыз?
Беркөн без дә картаербыз,
Үткән яшьлек үзәкне өзәр.

Бер үк ярны сөйгән чаклар...
Искә алыйк көлеп кенә.
Тик нигә соң кинәт кенә
Әче сүзләр әйттең чатнап?

Күңел-көзге — чәлпәрәмә!
Матур иде синең сурәт.
Яхшылыкка карыйк юрап.
Хуш, миләүшәм, үпкәләмә.

## Көндәшем

Сандугач шикелле сайрыйсың —
Җыр булып серләрең түгелә.
Сөйләмә берни дә, болай да
Бәхетең күзеңнән күренә.

Сандугач шикелле очасың —
Чакыра чәчәкле болының.
Нигә соң эндәшер чамам юк? —
Соп-соры чыпчыктай йомылдым.

Сандугач шикелле сайрыйсың...
Ул сине, тик сине ярата!
...Чыпчыклык хәленнән
чыгалмыйм.
Өздереп йөрәгем авырта-а-а.

## Таң

Төн әле. Күкләрдә агыла
Болытлар, кап-кара кайгыдай.
Бер елый, бер көлә шикелле
Шуларда тирбәлгән ялгыз ай.

Таң инде. Болытлар тарала.
Ай әнә китеп үк югала.
Төннәрне күрмәгән кыз бала
Кояшлы чишмәдән су ала...

## Язлар җитсә

Язлар җитсә, нигә йөрәк
Урыныннан кузгала?
Әйтерсең лә ялкын каба
Пыскып торган кузларга.

Нигә икән җанны ярып
Яшьлегем искә төшә?
Онытылган яшьлек ярым
Яндыра, язлар җитсә?

Нигә кирәк миңа хәзер
Үткәнне уйлап көю?
Бер сөенү, бер көнләшү,
Насыйпсыз ярны сөю?

Үткәндәге мәхәббәтем —
Гомерлек татлы серем.
Язлар аны яңарталар,
Кичер, бүгенге көнем!

## Сабантуй

Сабан туе тагын җиткән —
Әй җитез соң Вакыт!
Юкса язның тәмен дә бит
Өлгермәдек татып.

Сабан туен күрмәгәнгә
Инде еллар үткән.
Икебезнең оялчан җәй
Онытылган күптән.

Шул җәйдәге Сабантуйда
Үсмер чаклар калган.
Коеп яуган яңгырлары
Эзне юып алган.

Баксаң инде, ул җәйдән соң
Күпме вакыт үткән.
Икебезгә ике төрле
Юллар насыйп иткән.

Икебезгә ике бәхет
Бүләк иткән Вакыт...
Тик яшьлекнең Сабан туен
Өлгермәдек татып.

## Гипноз

Күзләр — кояш.
Күзләр — көзге.
Нурлар чагыла күздә.
Тик аңламыйм.
Ник аңламыйм?
Синең күзләрең — үзгә.

Кыймыйлар туры карарга.
Ниләр бар карашыңда?
Күзләрең тиештер кебек
Сүзеңә ярашырга.

Ә сүзләрең — ай ягымлы!
Ә сүзләрең — ай татлы!
Тик күрмимен күзләреңдә
Нурлар балкыган чакны.

Яшеренгән караштанмы
Якты балкыш көтәргә?
Күзләр — түбән,

сүзләр — матур...
Тизрәк синнән китәргә!

Офыккача йөгерергә,
Карамый алны-артны!
Мескен йөрәк сихерләнгән —
Татлы сүзләрең яклы...

## Йолдыз идем

Мин дә берчак
йолдыз идем.
Ялкыным сиңа күчте.
Күктән җиргә атылдым да
Салкын таш булып төштем.

Бүтәннәргә
нур бирсәң дә,
Үзең ялкынсыз калма!
Мин дә берчак йолдыз идем.
Шулкадәр дөрләп янма.

Кызыксыз бер матдә булдым,
Утымны сиңа биреп.
Мин дә берчак йолдыз идем
Нәкъ менә синең кебек...

* * *

Үзгәртте мәхәббәт:
Без хәзер көчле дә,
Матур да инде.
Изгелек иленә
Якын да инде.

Үзгәртте мәхәббәт:
Иң якты хисләрдән
Күңелләр тулы.
Киртәләр — вак нәрсә,
Без горур, без олы!

## Беренче  кар

Җанны дәшеп янар
хисләр учагына,
Беренче кар күбәләктәй оча гына.
«Кыш килә»,— дип,
яңа хәбәр китерә дә
Ашкына ул туган җирем
кочагына.

Сөенчегә: «Кияү килә!» —
дип кычкырып,
Авыл буйлап
нәни малай йөгергән күк,
Омтыла җир күкрәгенә
беренче кар,
«Өлгердем бит, өлгердем»,—

дип сөенгән күк.

## Мәхәббәтем микән?

Назландырып, ялындырып
Сөйдерүләрем истә.
Килсәң, нигә килдең, диеп
Көйдерүләрем истә.
Үкенгән чакларым булды,
Ник киттем, дип аһ орып,
Ялгызыңны ташлап киткәч,
Сагышларга батырып.
Горурлыгым булды микән
Килмә, дип әйтүләрем?
Мәхәббәтем микән инде
Һаман да көтүләрем?

## Гөлләр сере

Сөйләшәләр гөлләр, агачлар да...
Тик ишетү безгә язмаган.
Үз-үзебез белән артык мәшгуль,
Без югары, өстен яралган.

Ә гөлләр бит безнең өчен яши,
Ә гөлләр бит безне ишетә!
Чын күңелдән бүләк ителгәне
Чәчәк ата өзгән килеш тә.

Әйтелмичә калган сүзләрне дә
Гөлләр тоя, гөлләр сизенә:
Рәнҗегәндә күңел — безнең өчен
Чәчәкләрнең җаны өзелә.

Ник гөлләрне аңламыйбыз
икән? —
Сәбәпләрен әле тапмадым...
Беләсеңме, син китергән гөлләр
Минем өйдә чәчәк атмады.

## Шул гына

Нурлар, дисең,
балкып яна күзләреңдә,
Шатлык кына очрап тора юлыңда.
Кыен чакта дуслар белән
җиңел миңа,
Шатлыгымның бар сәбәбе —
шул гына.

«Син бәхетле,
елмаясың һәрвакытта»,—
Дисең миңа гаҗәпләнеп тагын да.
Кайгырмасын дус-ишләрем,
димен дә,
Аһ-зарымны сөйләмим мин —

шул гына.

Күздән яшем тамган иде,
тагын сиздең:
«Нишләп әле күңелеңдә
моң гына?»
Чын бәхетне яулап алу авырлыгын
Уйлап куйдым тирән сулап —
шул гына...

## Яратам

Ап-ак карга кемдер берәү
«Яратам» дип язып киткән.
Күз яшьләре хәреф булып
Карга эреп төште микән?

Йөрәгенә хисләр сыймый,
Кайсы егет кызын көткән?
Әллә бер кыз сөюенә
Җавап тапмый йөри микән?

Кар эретер кайнар сүзне
Әллә бергә язганнармы?
Кем белә бит...
                    Ни әйтсәң дә,
Яшерү кыен яратканны.

## Оялчан егет

Үткән саен карыйм тәрәзәңә,
Тәрәзәңдә калсын карашым.
Утың яна, пәрдәләрең ачык,
Үзең менә, үзең кая соң?

Тәрәзәңне юри ачкансыңдыр,
Мин сагынып карап үтсенгә.
Күз карашым гөлләреңдә калсын,
Сиңа тиңләп назлап үпсен дә.

Тәрәзәңә карыйм каерылып,
Йөрәксез ул, диеп көрсенмә.
Мин тартынам, хисем тапсын сине,
Тәрәзәңнән ташып керсен дә...

## Үзгәрү юк

Урыныннан тау купса да,
Кеше үзгәрми, диләр.
Ник шайтаннан иман көтәм
Гомер буе мин юләр?

Күрә торып күрмим берни,
Белә торып алданам.
Тау кузгатыр көчне, ахры,
Үз-үземнән табалмам.

Димәк, таулар күчми калыр,
Шайтан килмәс иманга.

Шул килеш яшәрмен инде,
Үзгәрү юк миңа да.

## Таң атканда

Менә тагын нурын сибеп,
Казанда ал таң атты.
Кояш нуры тәрәз аша
Чәчтән сыйпап уятты.

Мендәремне, юрганымны
Ут-нурлар урадылар,
Битләремнән үптеләр дә
Йокымны урладылар.

Шулар мине туган якка
Якынайттылар төсле.
Әллә минем сагынудан —
Таңнарда сагыш төсе...

## Үзе белә...

Кем икәнен үзе белә.
Берни әйтмим, сиздермим.
Үземнең дә сызлап торган
Яраларга тидермим.

Сөйләшәмен көлеп кенә.
Әллә чынлап минме бу?
Йөрәгемнән тамчы-тамчы
Кан тамызып тилмерү?

Кем икәнен үзе белә,
Карамый күзләремә.
Тик мин генә белмим менә
Күпмегә түзәремә.

Өстен булып калам шулай
Көлә-көлә сөйләшеп.
Җаным җиргә ятып елый
Җир белән тигезләшеп...

## Сихерче

Мин — сихерче,
мин — сихерче!
Күз тидердем бер парга:

Бәхетләреннән көнләшеп,
Күз сирпеп баккан идем.
Шатлыкларын чәлпәрәмә
Китереп аткан идем...

Мин — сихерче,
мин — сихерче!
Сөеп бактым бер парга:

Мин яратып караганга
Тормышлары да якты.
Ышанмаган ышанмасын —
Сихер көчле, канатлы...

Бармы тагын сихерчеләр?
Кемнәрнең күзе кара?

Мәңге бетмәс сихер белән
Үземә кем карады?
Гомер буе сызланырмын —
Аһ, йөрәгем яралы...

## Иске өй

Өй сүтәләр. Иске өй сүтәләр —
Урын кирәк яңа урамга.
Тик аңламый шуны алабай-эт,
Аякларга өреп урала.

Кешеләрнең сәер гамәленә
Эт акылы ничек җитсен ди?
Әнә инде күз алдында кими,
Юкка чыга чүгеп иске өй.

Өй сүтәләр.
Өй генә дә түгел...
Ямансулый әнә хуҗа да:
Үткән гомер, аккан сулар бит ул —
Уйлана да тагын кузгала.

Балалары үсеп, канат ярган
Җылыдан да җылы оя бу.
Дулкын каккан,
давыл кискән чакта
Бирешмәгән ныклы кыя бу.

Карлыгачлар оя корган нигез,
Үрмә гөлләр үскән бакчасы.
Ишегалларында — яшел чирәм —
Юкка чыга менә барчасы!

Өй сүтәләр, яңа фатирлары
Шәп тә шәбен, иркен, зиннәтле.
Тик сүтелә монда яшь гомерләр,
Хатирәләр сүтелә нихәтле.

Сурәте дә калмый
яшь гомернең,
Өе белән бергә югала.
Алабае шуны сизә бугай —
Аягына килеп урала.

Яңа фатир һәйбәт булуына
Эт акылы ничек җитсен ди?
Урамга да киңрәк урын кирәк,
Кичер инде, кичер, иске өй...

## Кайтырсың...

Сукбайлыкка чыктыңмы?
Оттырдыңмы, оттыңмы?

Арандагы ат идеңме?
Ирек сиңа ят идеме?

Тезгенеңне чиштеңме?
Җилләр булып истеңме?

Кояшка үрелдеңме?
Нурга әверелдеңме?

Чәчәкләргә кундыңмы?
Үзең чәчәк булдыңмы?

Асылыңа кайтырсың.
Оттырырсың, отырсың...

## Нәсыйхәт

*(Шаяру)*

Нинди назлы син, песием,
Нинди матур күзләрең.
Тик ирәймә, төннәр буе
Кайтмый йөрмә, юләрем.

Син бит минем юанычым,
Синнән башка күңелсез.
Егетмен дип батырайма,
Песи кызлары юньсез.

Көтмәгәндә, сүз берләшеп,
Кыйнап куярлар әле.
Уйламастан, дәрәҗәңне
Шулай җуярлар әле.

Йә күселәр тешләр инде,
Кичә дә кич кайтмадың.
Тормыш бит ул бик катлаулы,
Төнлә йөрмә, аппагым.

## Югыйсә...

Нинди күзләр,
нинди тирән караш! —
Сөйләми дә серен сыярлык.
Керфек какмый
карап торам да мин —
Күзләрен яшерә оялып.

Андагы наз, анда юмакайлык!
Һич бетмәгән нинди иркәлек!
— Чама белү кирәктер бит,—
димен,
Әрләгәндә үзен үртәлеп.

Әмма тугры! Эштән кәтеп ала,
Алларыма чыга көн саен.
Шундый иркә, куштан яралмаса,
Яши алмас иде, мөгаен.

Ярattыра үзен, кайгырттыра,
Сырпалана көннәр туды исә.
Бирсә биргән Ходай хәйләне дә! —
Песи генә бит ул югыйсә...

## Карга бураны

Җил сызгыра. Тәрәзәмне
Ярсый-ярсый кага буран.
Рухым белән язда идем,
Кышны ничек узыйм урап?
Кояш нурын күрсен, диеп
Тараттым да чәчләремне,
Ак бураннар күмеп китте...
Назлы җаным нишләр инде?
Күзләремне бәйләмә, кыш,
Коштай очам язга таба.
Бу бит — карга бураннары,
Күңелемә минем кага.

Бу бит — карга бураннары!..

## Минсез дә...

Ул күптән бит мине
Онытты, диярсең
Һәм бүтән берәүне
Өзелеп сөярсең.
Бакчада бөреләр
Кояшка үрелер.
Без йөргән юллардан
Гөрләвек йөгерер.
Бер ямьле бакчада
Сине ят яр көтәр.
Керфегең очына
Шук тамчы — наз төшәр.
Ул тамчы мин инде.
Торырмын аз гына.
Дөньяң, дип, минсез дә
Яз гына, наз гына...

## Сөенечкә

Йолдыз атылган чагында,
Кеше үлде, димә.
Йөрәккә йөрәк тартыла,
Мәхәббәтең килә.
Коеп-коеп яңгыр яуса,
Күңелсез соң, димә.
Яңгыр белән аралашып,
Җиргә муллык иңә.
Көзен яфрак саргайганда,
Сагыштан ул, димә.

Кояш төсле яфрак булып
Сөенечең килә.

## Бәрәннәр
## һәм адәмнәр

Сарык йоны алучының
Күз иярми кулына:
Әнкә сарык ярты еллык
Йон «тун»ыннан арына.
Арына да бәрәннәре
Янына китә чабып.
Алары да әнкәләрен
Барыбер ала танып.
Кайчакта ярый безгә дә
Ияргү шул үрнәккә:
Яшәүнең түгел хикмәте
Яңа кием, күлмәктә.
Күпме генә көязләнмик
Көзгедән карый-карый,
Күзебезгә карау белән
Кешеләр безне таный.

## Оптимистик
## шигырь

Сарафан сатып йөриләр.
Аны кияр җәй бармы?
Кояш көтеп үткәрәбез
Яңгыр койган айларны.

Белми кояш көткәнне дә,
Туктамый яңгыр ява.
Күңелләре җәйдәгеләр
Сарафан сатып ала.

Кемгәдер көз, кемгәдер җәй —
Яумаса ни, яуса ни?
Булсын гына! — яңгыр итеп
И сибәләр акчаны.

Сарафан сатып йөриләр.
Алучысы бер олау!
Иртәгәдән чыгар кояш.
Явып кал син, яңгыр, яу!

Сарафан алучыларны
Болыт та күрә инде:
Өметләрне алдау оят —
Офыкка чигә инде.

## Егет булмыйк әле

«Егетләрчә» дигән мактау сүзе,
Миңа калса, чыкты модадан.
«Егетсең!» —

дип хупласалар кинәт,
Кызлар кебек никтер кызарам.

Егет булмыйк әле, хатын-кызлар.
Анда — ваклык, эчү, гайбәте...
Тел чарлыйлар
хатын-кызны сүгеп —
Егетләрнең шулмы гайрәте?

Ходай биргән ирлегеннән башка
Горурланыр сәбәп калмагач,
Хатыннардан күлеп ләззәт ала
Ир дигәнең — шулай ярагач.

Бик күпләрен,
пирчәткәмне ташлап,
Дәшәр идем атыш-дуэльгә.
Тик шикләнәм, йөзен яшермичә,
Каршы чыгар икән кем генә?

Егет булмыйк әле, хатын-кызлар.
Өстен калыйк мондый ирлектән.
Ходай биргән хатын-кызлык ямен
Саклап яшик җирдә ничек тә.
Егет булмыйк әле,
хатын-кызлар...

## Сау булыгыз, китәм...

Сикерә дә чыга, әрсезләнеп, телем.
Шул телемне җиңсәм,
әйбәт яшәр идем.

Дәшмәм, дигәнем бар, әйтмәм,
дигәнем бар,
Телләремне тешләп,
башым игәнем бар.

Дәшми калу — рәхәт,
сүзсез тору — рәхәт.
Түзеп булса икән шулай
рәхәт яшәп.

Күбрәк күреләә шул,
ишетелә күбрәк,
Күкрәгемә сыймый
бәргәләнә йөрәк.

Пырдымсызмы үзем,
каян алыйм түзем?
Әйләнә дә кайта
әйтмәм дигән сүзем.

Инде вәгъдә итәм:
алай итмәм бүтән.
Үз-үземне алдап, үз-үземнән китәм!

Китәм, китәм!
...Йөз меңенче кабат:
алай итмәм бүтән!

## Хикмәт

«Хөкүмәтнең исе китсен»,—
Дия иде бер танышым.
Мактанып йөргән кешегә —
Чуалтып фикер агышын.

Мактанчыгы, ялганчысы
Очрап тора — нинди хикмәт!
«Хөкүмәтнең исе китсен!» —
Дип әйтәсе килә иплэп.

Тик шунысы: бу сүзләргә
Кайсысының исе китәр?
Әүвәлгедән дә арттырып,
Үз шөгылен дәвам итәр.

Мактанчыкның, ялганчының,
Хәтта бурның почеты зур.
Фәрештә сыман кылансаң,
Үзең генә булырсың хур.

Чиктән узган азгыннарга
Кинаяләр барып җитми.
Чөнки ниләр кыланса да,
Хөкүмәтнең исе китми.

Хөкүмәтнең исе китми!

## Ташкалага кем баш кала?

— Таш калага кем баш кала? —
Сөрән салды кем башлап?
Җәлт! — җыелды бала-чага,
Чаңгы-чанасын ташлап.

Таш калага кем баш кала?
Таш каласы — кар тавы.
Ава-түнә үрмәлиләр,
Тарта-тарта танауны.

Таш каласы, ай-һай, биек,
Юлдаш юк менүчегә.
Үргә үзе менү өчен
Дуслар дуска үчегә.

Таш каланың итәгендә
Яталар да тәгәрәп,
Өстәгене өстериләр
Тагын тауга үрмәләп.

Ил башының да урыны
Кар тавыннан киммени?
Кар тузаны туздырганда,

Ил күзгә дә күренми.

Таш калага патша башмы? —
Төшерәбез бәргәләп.
Әллә кемнәр тарткалашып
Кала шунда тәгәрәп.

Ленин башмы? — шап башына,
Күптән срогы чыккан.
Сталин менгән тау башына —
Кулына мылтык тоткан.

Таш калада калу кыен.
Башлар килә дә китә.
Йә бу башны, йә тегесен
Типкәләп гомер үтә.

Горбач кыйный Сталинны,
Ельцин суга Горбачка.
Таш каладан тузан туза,
Тик бу мәсьәлә — башка.

Таш калага кем баш кала?
Сөрән салалар һаман.
Үрмәлиләр — белсәләр дә
Бер тәгәрисен аннан.

Өстерәшә-тарткалаша
Җимерәләр кар тавын.
Тик бер максат —
Баш булырга!
Алла белә калганын.

## Чәйгә чакыру

Күчтәнәчең нигә кирәк,
Үзең булмагач янда?
Сый-хөрмәтем өстәл тулы,
Берни юк кебек алда.

Тәм-томсыз да эчә алам
Бер чынаяк чәемне.
Күчтәнәчкә үзең килсәң,
Вакытың җәл идеме?

Мин андый ук әрсез түгел,
Сине кабып, чәй эчмәм.
Син янымда булган чакта,
Су да татлы — чүмечтән!

Күчтәнәч кирәк, дидемме? —
Шаярттым да оныттым.
Сыйланырга утыр, әйдә,
Кызганма биш минутың.

Миндә дә бит шул ук вакыт.
Артыгы бирелмәгән.

Чәйләү өчен бердәнбер шарт —
Күчтәнәч, диелмәгән.

Бергә-бергә чәй эчүнең
Күчтәнәчтәме яме?
Моннан соң берни сорамам,
Үзең генә кил, яме?

## Һавасыз...

Мин бит сиңа һава кебек идем,
Хәлең ничек хәзер, һавасыз?
Бардыр дустың,
бардыр сердәшең дә,
Ә һаваның булмый яңасы.

Мин бит сиңа һава кебек кирәк,
Суламыйча ничек яшисең?
Тел тибрәтеп, кил,
дип дәшәр идең,
Миннән башка, беләм, ятим син.

Үз-үземә зур бәядер, бәлки?
Әллә сиңа шулай ышанам?
Уйны уйга, җанны җанга ялгап,
Күңелемнән сиңа юл салам.

Тел тибрәтеп, үзең чакырмагач,
Синең якка юллар өзек бит.
Үрсәләнеп сөрән салуым бу:
— Мин бит сиңа
һава кебек! — дип.

## Исеңдәме?

Исеңдәме Казан урамнары,
Күккә ашкан биек-биек йортлар?
Безгә карап, бәхет юрагандай,
Күз кысышкан аллы-гөлле утлар?

Икәүләшеп очып уздык бугай
Иксез-чиксез озын урамнарны.
Җаныбызны, җылы өермәдәй,
Бары шатлык, шатлык урап алды.

Исеңдәме, яңгыр яуган иде.
Җитәкләшеп, гөрләвекләр кичтек?
Бөтен Казан карап торган чакта,
Алдыбызга күктән йолдыз төште.

Кулларымны алып кулларыңа,
Йолдыз йөзгән гөрләвектә юдың.
Кулым гына түгел, бөтен тәнем,
Җаным белән садә-чиста булдым.

Исеңдәме болар, исеңдәме?

Дәшмисең һич, димәк, төшенмисең.
Кичер берүк, үзем генә күргән,
Үзем генә белгән төшем ич син!

## Син курыкма

Син курыкма
минем шигырьләрдән:
Алар синнән берни өмет итми.
Җаным бары:
«Дөнья ваклыгыннан
Тик беразга мине азат ит»,— ди.

Мин яшерәм арып-талган җанны,
Кайнар хисләремә төреп-төреп.
Ямьсезлектән ямьнәр эзләштереп,
Бәгыремне парә-парә телеп.

Мин яшерәм яшьле күзләремне
«Яратам» дип язган шигыремдә,
Кешеләре бер кадерсез булган
Тоташ борчу, мөтәгамь илендә.

Һич югында сөйгән, сөелгәннәр
Бәхет тапмасмы, дип,
җир йөзендә,
Сиңа булган хисләремне сөйлим
Янып-көеп язган шигыремдә.

Син курыкма минем хисләремнән,
Минем сөю учак булып янсын.
Өшегәннәр, күшеккәннәр килеп,
Учагымнан җылы таба алсын.

Син курыкма минем сөюемнән...

## Син

Сабыр савытларым тулган чакта
Чайпалдырмый
тотып торучы — син.
Иләсләнеп, хисем кузгалганда,
Гаеп итми йотып торучы син.

Эндәшмичә газап өстәүчем дә —
Тилмерепләр синнән сүз көткәндә.
Кытай дивардай — ышанычлым.
Суга таянгандай — шик-шөбһәм дә.

Ни могҗиза:
тоташ каршылык син...
Шул килеш тә —
җанның иң түрендә!
Мин таянам сиңа таш дивар дип:
Рисвай итмә авып ил күзендә.

Һәм битараф кына була күрмә,
Тап үзеңдә сыендырыр көчне.
Үзең кебек тоташ кытыршылык,
Каршылыктан торган
минем хисне.

# Бәллүр касә

## Гашыйк

Кулларыңны куйчы маңгаема,
Сизәсеңме, ничек яна башым?
Күзләреңә кереп адаштыммы,
Канатланып күкләргәме аштым?

Рухым бүген әллә кайда йөри...
Кайнар башым —
синең алларыңда.
Күзләреңә карап талпындым да
Былбыл булдым сөю аланында.

Сүзләр артык, йөрәк кенә сөйли.
Хыялый мин синең яннарыңда.
Их, шул килеш җырга әйләнергә,
Әкияткә барып ялганырга!

Хәйләсездер бу хыялый сөю,
Мөмкин түгел хистә алданырга!
...Мин тезләнеп
сәҗдә кылам бүген
Мәхәббәтнең ихлас ялганына...

* * *

Мне нравится,
что я больна не Вами...
*Марина Цветаева*

Сезнең күзләрегез ошый миңа:
Йә бик моңлы, йә бик шаян алар.
Көләсез дә — йөзегезне нурлап
Чокырчыклар уйнап шаяралар.

Шаяртуларыгыз ошый миңа —
Аңлаучылар бармы
миннән башка?
...Күңел генә гел яшьлектә кала,
Бәсләр төшә юкса безнең башка.

Җырлавыгыз бик тә ошый миңа:
«Герман көйләре»ндә
күпме сагыш!
Сез җырчы да түгелдер дә, бәлки,
Ошый миңа, ошый Сезнең тавыш.

Хисләремнең иң-иң ихласлары —

Сезгә багышланган җырым шушы.
Хыялымда гына калыр өчен
Башканыкы булуыгыз ошый!

## Аңларсыңмы?

Ятлар җаны — карурмандыр.
Ә соң миңа ятмы син?
Уйлап кына тапкан сурәт —
Әкияти затмы син?

Синең җаның — минем иҗат:
Урманың да яктыдыр.
Якты диеп инанганга
Җиләкләре татлыдыр.

Ятлар җаны — карурман да...
Ә мин сиңа ят микән?
Синең хыял дөньясында
Каеннарым ак микән?

Каеннарым ак микән дә
Чишмәләрем саф микән?
Аңларсыңмы күңелемне,
Онытылып: «Аһ!» — дисәм?

Тик үтенәм: бер көн килеп,
Җанымнан әгәр китсәң,
Урманыбыз якты калсын,
Чишмәләр калсын исән!

## Яшь аралаш көлү

Син бу җиргә яратырга түгел,
Ярattырыр өчен яралган.
Белеп торам, сиңа гашыйк булам
Өр-яңадан, тагын яңадан.

Җитми сиңа минем сөю генә:
Күпләр сөйсен, күккә ашырсын.
Күреп торып,
шундый уйнак җанны
Яратуы бигрәк авыр соң!

Таһир өчен җанын кызганмаган
Зөһрә сыман үлсәм әгәр дә —
Сөенечтән күтәрелер идең
Күкләрдән дә биек мөнбәргә.

Яраттыру өчен җаның фида —
Үз-үзеңне артык сөясең.
Зөһрә булып, синең өчен үлсәм,
Сөенечтән... син дә үләрсең!

## Бәлки...

Җилләр безгә гел-гел каршы исә,

Йолдызнамә бәхет юрамый...
Борынгыдан килә: беркем әле
Язмышларны кире боралмый.

Бер-беренә каршы агып барган
Елгалардай яши бирәбез.
Без — арада чиксез бушлык яткан
Ике полюс инде — беләбез.

Җәйге таңда җирдән күтәрелгән
Томан булып икәү берләшсәк —
Бәлки әле яр таллары бездән
Мизгелләрне санап көнләшмәс?

Гасырлардан бирле ике якка
Язмыш-ярдан узмый акканга —
Мәхрүм итмәс, бәлки,
                                    каршы җилләр
Биеклеккә ашкан чаклардан?

Яр буенда ак томаннан оеп,
Йокласыннар көнче таллыклар...
Мәңгелектән мизгел генә бит бу! —
Язмыш безне, бәлки, ярлыкар?

## Йолдыз нуры

Сабырлыклар җитсә, бу кадәр үк
Өзгәләнмәс идем ләбаса.
Синең өчен — уен... чираттагы...
Минем өчен — әрнү дә хафа.

Күзләреңдә — ят йолдызлар нуры.
Хыялларым тиңләп канатка,
Очар идем — шул йолдызлар җиле
Канатларны сугып каната.

Әллә уйлап, әллә уйнап шунда
Фәрештәгә тиңләп юатма!
Араларда хәтта гадиләр дә
Кичәлмәслек озын юл ята:

Утлы йолдыз юлы...
                                 Язмышларны
Юл яздырып сыный, уйната.
Сиңа кызык: күзләреңдә — ләззәт!
Минем җанда бетмәс моң ята.

## Чың

Якын килмә миңа —
                                мин бәллүрдән.
Якын килмә — хәзер уалам.
Чәчеләм дә челпәрәмә килеп,
Күз алдында бетәм, югалам.

Якын килмә миңа: синең килү —

Сил ташканда купкан җил кебек.
Бәллүр йөрәк калтыранган саен,
Ватылырга тора җилкенеп!

Ватылырга торам, кызган мине:
Якын килмә, саксыз кагылма
Синең силдән чак-чак исән калган
Чыңлап торган бәллүр җаныма.

Минем язмыш кыл өстендә бугай.
Соңгы чикне юкса тоясың...
Синең дөньяң гаҗиз торыр бертын
Бер чыңлаудан бары —
                                        чың, чың, чың!..

## Кара урман

Ярата дип, йөрмә кәперәеп,
Син тугансың минем хыялда.
Кара урман кебек билгесез син,
Ниләр булмас кара урманда?

Ача калсам кара урман серен,
Яратмам да, бәлки, иртәгә.
Мин бүгенгә хыялыма гашыйк,
Горурлыгың белән үртәмә.

Болыт арасыннан бер күренеп,
Бер күмелеп калган ай сыман,
Йөзеп кара, әйдә, чиксезлектә,
Иртәгә мин сине юксынмам.

Иртәгә мин сине онытырмын,
Хыялымнан кинәт бушанып.
Мин үзем дә — кара урман әле,
Кичерер дип йөрмә ышанып.

## Коръән арасында калган хат

Хәзер инде могҗизаны
күрдегезме?
Бездән өстен язмышларга
күндегезме?
Хыял кала хыял килеш —
белдегезме?
Гамәлләргә тик бер Алла
хуҗа булыр.

Учак булып
күп тапкырлар яндыгызмы?
Очкыннарга сулыш өреп
ардыгызмы?
Яна-яна кайнар көлгә
калдыгызмы?
Яңа уттан тик бер Алла
саклап торыр.

Язмыш саклый ялгышлардан —
тойдыгызмы?
Хәтерегезгә гомерлеккә
уйдыгызмы?
Гөнаһлы уй,
буш хыялны куйдыгызмы?
Сездән мине тик бер Аллам
яклап торыр.

Бәхет юрап йолдызнамә
ачтыгызмы?
Уегызда үткәннәрдән
качтыгызмы?
Былбыл булып һаваларга
аштыгызмы?
...Раббем Аллам! Ярлыкагыл,
ярлыкагыл...

## Каршылык

Син яшеннәр эзләп китеп бардың,
Карашыңда — яшен сурәте.
Хыялыңны читкә алып киткәч,
Болытларны килми күрәсем.

Яшеннәрдән ниләр көтәсеңдер,
Сызыла да үтә — бер мизгел!
Сабыр савытларым яңгыр юа,
Тамчылары инде йөз, меңдер.

Син яшеннәр эзләп йөргән чакта,
Болытлы көн — минем халәтем.
Мин бер мизгел түгел
яшен кебек,
Мин яратмыйм яшен сурәтен.

Җылы биргән җир учагын сөям,
Син — яшенне. Ничек әрнетә!
Икебез дә утка гашыйк юкса,
Ике якта язмыш йөретә.

## Минем исем

Китәрсең дә югалырсың,
Күңел кырында бер гөл...
*(Усал шаярту)*

Китәрмен дә югалырмын,
Төшмәм хәтта исегезгә.
Телгә керсә, төртелерсез
Минем кыен исемемә.

Һәр сүзегез тиеш чакта
Энҗе кебек тезелергә,
Ачуыгыз килер микән
Көрмәкләнгән телегезгә?

Таң гөлләре әзер чакта
Сезнең өчен өзелергә —
Минем исем... сезнең телне
Буйсындырмас үзегезгә.

Гөл чугыннан тамган чыкны
Киптерергә күзегездән,
Кояш булып балкучыны
Сизмәссез дә күгегездә.

Күңел-кырда гөлләр чиксез...
Тезгән чакта түшегезгә —
Китәрмен дә югалырмын.
Кермәм хәтта төшегезгә!

## Соңгы чакыру

Син ай булсаң,
мин — кояш...

Мин ашыктым һаман,
син соңладың.
Син соңладың никтер гомер буе.
Ятлар читтән бәя биргән булды:
Бер-берендә, дип, боларның уе.

Читтән безгә бәхет юрадылар,
Тик безгә ул тоттырмады һаман.
Син, ай булып,
кичен калыккансың,
Ә мин яндым, кояш булып,
таңнан.

Хыял аша бергә булганда да,
Көннәр аяз икән, төннәр якты.
Мин ашыксам, син соңлама инде.
Таң атканда әллә йоклар чакмы?

Сүрәнлегең айдан күчкәндер шул,
Ут-ялкыннар миңа — таңнардан.
Мин соңгы кат, бәлки,
эндәшәмдер,
Син: «Соңламам,— диген,—
соңламам!»

## Янмый учак

Янмый учак, янмый учак.
Төтен генә бөркелә.
Әчесеннән күзләремне
Ачалмыйча интегәм.

Пыскый учак, пыскый учак —
Төтен исе чәчемдә.
Җил иссә дә ялкынланмый,
Көле генә чәчелә.

Төтен әчеседәй кисеп,

Тамагыма бөяла
Синең исем... Калдың ничек
Үткән утлы көннәрдә?

Учакларың исән микән?
Бардыр сиңа тиңнәр дә...
Синле көннәр сагыш булып
Баса минем иңнәргә.

Шатлык — парлы,
сагыш — сыңар.
Учак янмый интегә.
Өмет тулы күңелемә
Төтен генә бөркелә.

## Күңел генә бушап калды

Күрер күзне күрмәс итәр
Сихер бар микән әллә?
Кабындыммы учак булып
Син үтеп киткән мәлдә?

Син йөземә караганга
Яшердемме күзләрем?
Төшләремдә адаштың да
Саташтырдың төннәрен.

Өметләнеп көтмәсәм дә,
Хыялыма тимәдем.
Дөньямда син булган өчен
Якты иде көннәрем.

Вакыт үтте, әфьюн сыман
Сихер китте тәнемнән:
Буш хыялга башны иеп,
Ничек төссезләнелгән!

Әле ярый, айныдым да
Чыктым көлке хәлемнән.
Күңел генә бушап калды,
Бушап... яшьлек яменнән.

## Яфрак хәлендә

Бик сагынды сине бакчам,
Гөлләрем көтә, димә.
Үзем сагындым, диген син,
Горур башыңны и дә.

Күңелеңдә ниләр барын
Күреп булмый үтәли.
Хисләреңне яшермичә
Әйтү кыен микәнни?

Сизәм дә, сизмим дә кебек

Тартыну сәбәпләрен.
Яфрак кебек саргайтасың —
Их, шушы гадәтләрең.

Сүз яшереп, тел яшереп,
Күпме була йөрергә?
Кил бакчага, көтәм, диген!
Гөлләрем көтә, димә!

Килермен дә... яфрак итеп
Өзеп алыр җил генә...
Әйт тизрәк, көтәм, диген!
Бакчам сагынды, димә!

## Әбиләр чуагы

Ява яфрак яңгырлары —
Кызыл-сары, кызыл-сары.
Кызыл-сары күбәләк тә
Яфрак булып оча тагы.

Әйтерсең лә маскарад бу,
Карагызчы керфек сирпеп —
Яфракмы соң, күбәләкме,
Канатларын куя җилпеп?

Кызыл-сары, кызыл-сары,
Бердәй матур икесе дә.
Кунсын әле чәчегезгә.
Сокланыгыз көз төсенә.

Ява яфрак яңгырлары,
Тылсымыннан торам оеп.
Кызыл-сары тамчыларга
Учларымны ачып куеп.

## Баян

Онытылып көлгән чагым иде.
Бу сагышлар иңде кинәт каян?
Миңа карап, эчтән сызды бугай
Безнең белән гомер иткән баян.

Вакыт — табиб,
дәваламый калмас.
Йомылыр әле син ясаган ярам.
Ләкин калыр гарип җанлы булып
Безнең белән гомер иткән баян.

Синең белән китсә ярты җаны,
Ярты җаны аның миндә калган.
Чит күзләргә бөтен кебек үзе —
Безнең белән гомер иткән баян.

Безнең яшьлек
моңнарына тугры...
Бернигә дә алмаштыра алмам.

— Син онытма, хет син,—
дия кебек
Безнең белән гомер иткән баян.

## Автопортрет

*(Шаяру)*

Серле дөнья эзләп адаштыммы?
Барган саен — куе чытырман.
Күңел белән биеклеккә ашам,
Төп башына килеп утырам.

Үз-үземнән көләм ачы итеп:
— Әйдә инде, юлың ачыкла!..
Кайчагында, юкны эзли-эзли,
Әвереләм метер карчыкка.

Кычкырынам, бәйләнәмен юкка:
Анда гаеп, монда кыек бар...
Аңа карап, чикми чытырманым,
Баш очымнан китми болытлар.

Серле дөнья эзлим: а-у, а-у!
Яктылыкка, имеш, юл тотам...
Ә каршыма, чытырманнар аша,
Шүрәлеләр чыгып куркыта.

## Аккош күле

*Гүзәлгә*

Сагынып кайтыр күле була
аккошларның —
Ымсындырып яз чакырса
туган якка.
Зәңгәр күле ихлас сөю бүләк итәр,
Аккошкае сәлам биреп
канат какса.

Күл-көзгенең күңелкәе
хистән тулы:
Хыялында бер дә китмәс
аккошы бар.
Шуңа күрә төнбоеклы күзләреңдә
Мәңге сүнмәс илаһилык
балкышы бар.

Чынбарлыкта һәм хыялда —
ике аккош...
Их, икесе бер җан булып
канат какса!
Күл бу хакта уйларга да
җөрьәт итми,
Аккош кунгач,
чайпала тик алка-алка...

## Яңгырда

Әллә яшем, әллә яшен
Чагылдыра күзләремне.
Яшеренмим яшеннәрдән —
Тик син генә якла мине.

Юлларыма койган яңгыр
Елга булып аккан инде.
Чыдармын ла яңгырына —
Кар-бозыннан сакла мине.

Яланаяк сулар кичтем,
Кыен чаклар артта инде...
Сөйләгәннәр сөйләсеннәр —
Шулай да син акла мине.

Таянычым булалмасаң
Каккан-кискән чакта җиле —
Авыр булыр, тик түзәрмен —
Син кызганма, ташла мине!

## Юату

*Эльмирага*

Боегып калган кара җирне
Күмеп китсен ап-ак буран.
Шикләреңне читкә ташлап,
Син дә акка, акка уран.

Бу дөньяны, хәрәкәтне
Юк, без уйлап чыгармаган!
Ул бүген дә төрле төсле,
Кичә дә нәкъ шулай булган.

Иртәгә дә шулай булыр.
Ә син бүген — акка уран!
Бу үзе бер фәлсәфә бит:
Юккамы син кышта туган?

Ап-ак кышта тугансың син,
Ә дөньябыз — гөлләр төсле!
Барысын сөеп кабул итик
Читкә ташлап төрле шикне.

## Күз

Яратам дип нигә көчәнәсең?
Күптән сүнде учакларның уты.
Алмагачлар яфракларын койды,
Кәүсәләрдә туңды яшәү суты.

Алма-бакча сөю хатирәсен
Сары яфрак итеп җиргә түши.
Мин, күшегеп, шәлгә төренәмен,
Әллә тәнем, әллә җаным өши.

Җылытмакчы булып үреләсең,

Сизмисеңме җаным үртәлгәнен?
Бер үк учак янмый ике тапкыр,
Онытылды сине көткәннәрем.

Мин көткәндә
син кайларда идең?
Яратам дип көчәнәсең хәзер.
...Бер кошмы соң
ялгыш сайрап куйды? —
Яз көннәрен искә төшерәдер...

## Кышкы чишмә

Ап-ак карлар зәңгәр күләгәле,
Челтәр шәлдән яшел чыршылар...
Күңел тагын бер кат иләсләнер,
Көмеш чишмә булып чылтырар.

Ап-ак карга эзләр сала-сала,
Язга таба атлап китәрмен.
Көмеш чишмәм эретер салкыннарын
Зәңгәр күләгәле көртләрнең.

Бөтерелеп аккан зәңгәр бозда
Саубуллашкан кебек ут янар...
Китми тор, кыш!
Минем чишмәм әле
Кар астыннан, бәлки, юл табар.

## Бәсле теләк

Урманнарга керик бәсләр коеп,
Тормасыннар йоклагандай оеп.
«Яңа е-ел!» — дип
аваз салыр җилләр,
Һәм болытлар
йолдыз-карын сибәр...
Җем-җем итәр безнең киемнәрдә!
Тылсым көче бардыр бу көннәрдә —
Уй-хисләрнең иң сафлары калыр,
Киләчәккә безне алып барыр.
Яңа елга бары шундый теләк!
Күрәсезме, бүләкләрен төяп,
Кыш бабай да инде юлга чыкты:
Агачлардан коела ап-ак сыкы.

## Үкенеч

*Рөстәм*
*Мөхәммәтҗановка*

Язгы бакча, кошлар сайрый,
Чәчәкләр — түтәл-түтәл...
Кемнедер көтә зарыгып,
Ак урындык, ак өстәл.

Фәрештәдәй бер асыл зат
Ашыкмый гына килер.
Үзен дәшкән фоторәссам

Күптән монда дип белер.

Әмма рәссам бәйрәм итәр,
Эш турында онытыр.
Шәраб тулы чәркәләре
Шаярыр чылтыр-чылтыр.

Фәрештәдәй асыл заты
Күтәр-күтәр дә китәр.
Төн челтәрен ябынып йоклар
Ак урындык, ак өстәл.

Өр-яңадан туар оста
Иртәгә таң атканда.
Фотоаппаратын асар да
Чабар теге бакчага.

— Илле яшем тулды, — диеп,
Акланыр чәчәкләргә...
Тик, кил, диеп фәрештәгә
Ничек кабат дәшәргә?

## Су буенда

Комлы ярга дулкыннарын кагып,
Безнең белән елга шаяра.
Дулкын-дулкын еллар
кергән инде
Синең белән минем арага.

Еллар гына нәрсә? Гомер, гомер...
Сүтәргәме хәтер йомгагын?
Сулар ага, яңа дулкын юа
Тын ярларның кайнар комнарын.

Безнең ярлар иде, безнең елга.
Башка сулар хәзер, башка ком...
Яшьлегебез исән әле җанда,
Күпме сулар гөрләп акмасын.

Агымсуга салыйк серебезне,
Бар дөньяга, әйдә, таратсын:
Ярын һичкем ятка калдырмасын.
Бары үзе, үзе яратсын!

## Тукталыш

Бар сәгатьләр туктап калды
Без бәхетле минутта.
Сулыш алмый торды дөнья —
Талды сихри тынлыкка.

Бар сәгатьләр туктап калды,
Изге мәлне тоткарлап.
Бер тавышсыз канат кагып,
Очып узды акчарлак.

Тавышсыз гына чайпалып,
Дулкын какты ярларга.
Безнең йөрәк тибеше тик
Китте әллә кайларга.

Әллә кайларда яңгырап,
Кайтаваз булып кайтты.
Туктаган мизгелне узып,
Алсуланып таң атты.

Тынып калган серләр илен
Кузгатты безнең йөрәк!
...Тек-тек итеп, тек-тек итеп,
Йөри башлады сәгать...

## Фараз

Чәч учмамда кулың назы калды —
Маңгаема ялгыш кагылдың да...
Шул да җитте, китеп өлгергәнче,
Кулларыңны янә сагынырга.

Чәчләремнең дөрләп кабынуын
Сизми калмагандыр бармакларың.
Телең йоттың, элеккечә көлеп,
Төртмә сүзләр әйтеп шаяртмадың.

Күзем сирпеп карарга да куркам.
Карашыңнан якты нур чагыла.
Бармакларың кире кайтыр кебек
Чәчләремә яккан учагыңа.

## Син киткәч

Тәрәзәмне ачтың — җил уйнады.
Тәрәзәмне ачтың — җил керде.
Йөземдәге учакларга өрде.
Йөрәгемә ташып сил керде.

Йөрәгемне агызып ла китте...
Тәрәзәмне яптың — нишләдең?
Тәрәзәмнән кояш нуры керде.
Кояш нуры булып төшмәдең.

Йөзләремдә — учак урыннары...
Сизәм, сизәм җанны өткәнне.
Тәрәзәдән күзем алып булмый:
Карап торам синең киткәнне.

## Ясалма гөл

Янып торган кызыл гөлләр!
Чак сыйдырган кочагына.
Шул егеттән күзем китми.
Зиһен әйтә: «Юкка гына!»

Егетендә бер эшем юк,
Гөлдән туймас күземдер бу.

Нәрсә зиһен? Матурлыкка
Гел мөкиббән үземдер бу.

Кайсы гына бәхетлесе
Лаек икән шул гөлләргә?
Берсен генә миңа бирсә...
Мин кемнәндер кимме әллә?

Сабый кебек нәүмиз торам,
Чәчәклрәдән күзем китми.
Нигә миңа беркем бүген
Кызыл гөлләр бүләк итми?

Тукта, чү, дим, егет миңа
Бер чәчәкне сайлап алды:
Гөл бәйләме тере иде,
Каян тапты ясалманы?

Ясалма гөл сузды көлеп,
Үзе инде китеп бара.
Гөлгә карап нәүмиз торам,
Әйтерсең лә сабый бала...

## Юл догасы

Озын юлларга кузгалган чагың,
Ул юллар сине кайларга илтер?
Күңел түремдә бер теләк кала:
Син юлда мине исеңә төшер.

Урау-урау булса барыр юлың,
Адаштыргыч язмышыңны кичер.
Берни көтмим, өмет итмим синнән,
Тик мине бары исеңә төшер.

Урау язмышлардан үзем гаҗиз,
Синең хакта уйлавым да көфер...
Юлларыңда бәхет табыйм, дисәң,
Барыбер мине исеңә төшер.

Ялгызым китәм, диеп уйлама,
Юлдашка җырым кузгала, шөкер.
Урау юлың да кире кайтарыр —
Тик мине... мине исеңә төшер!

## Кем әйткән?

Мәхәббәт бәхет, дип,
Кем әйткән һәм кайчан?
Ярату — шатлык, дип,
Яңалык кем ачкан?

Кем әйткән, ни өчен?
Нигә соң алдашкан?
Мин дә бит яратам —
Чыгалмыйм газаптан.

Зарымны тырышам
Йөрәккә бикләргә.
Серемне сөйләргә
Дустым юк, нишләргә?

Каршылык корганнар
Безнең һәр адымга.
Күпмегә куярлар
Киртәләр тагын да?

Ул да бит ярата,
Чыгалмый газаптан —
Ярату рәхәт, дип,
Кем миңа алдашкан?

## Хуш!

Әгәр сине туйдырганмын икән,
Сәбәп эзләп йөрмә китәреңә.
Гомерләрем зая үтә, дисәң,
Каршы төшмәм синең шикләреңә.

Үз жаныңны,
минем жанны кыйнап,
Сәбәп кенә эзләп йөри күрмә.
Курыкканым:
син кош булсаң әгәр,
Булмасамчы сиңа читлек-төрмә.

Кызганулар белән түбәнсетмә,
Бар сәбәпләр —
дөреслектән мескен.
Хакыйкатьне кабул итәр йөрәк,
Ялган гына —
хәнжәрләрдән үткен.

Чын дөресен күтәрермен, димен,
Ялган хәнжәреннән исән калмам.
Оч еракка, кош йөрәкле дустым...
Ярлыкасын сине газиз Аллам!

## Тынгылык бир!

Тынгылык бир, тынгылык бир,
Үзең дә бер тынычлан.
Беләсең бит — бу йөрәкләр
Коелмаган корычтан.

Тынгылык бир, тынгылык бир,
Күләгәңне юлдан ал.
Икәү йөргән аланнарны
Күмеп китсен бураннар.

Икәү бергә кичкән жәйнең
Яктылыгын уйламам:
Кояш төшкән аланда да
Кара шәүлә уйнаган.

Монда безнең кәккүкләрнең
Йөрәкләре ярылган.
Бер могҗиза — тынгы көтәм
Килер кышның карыннан.

Тынгылык бир, тынгылык тап —
Бураннарда югал да!
Йөрәкләр шул — кәккүкләрчә...
Корыч түгел алай да.

Югал, зинһар! Ә мин, ахры,
Шул аланнан айрылмам:
Монда безнең кәккүкләрнең,
Ел санаган кәккүкләрнең,
Бәхет көткән кәккүкләрнең
Йөрәкләре ярылган бит,
Йөрәкләре ярылган...

***

Рәхәт лә ул акыл белән
Фикер йөртү,
Чит-ятларны үз кысаңа
Төртеп кертү.

Янәсе, мин алай булмам,
Болай булмам,
Иләсләнеп беркайчан да
Гөнаһ кылмам.

Башкаларның ялгышлары
Күренә шул.
Гаебенә, гайбәтенә
Керелә шул.

...Язмыш җиле уңга кагар,
Сулга кагар —
Зиһен сүнәр, йөрәгеңә
Утлар кабар.

Зилзиләдән сукыр калыр
Күзләрең дә...
Бар ышаныч дөрләп торган
Йөрәгеңдә...

И беркатлы аек акыл!
Сынап кара:
Иләсләнү хәлләренә
Чыдап кара!

## Туйлар илә уйлар...

Җиде диңгез кичәсең,
Каф тауларын үтәсең –
Әкиятләрдә язылган
Батырларга ияреп.

Тарактан урман үсә,
Күл булып — күзге төшә...
Хәсрәтләрдән коясең,
Каеннарга сөялеп.

Күтәрелеп тәхеткә,
Ирешәсең бәхеткә,
Кырык көн туй итәсең,
Хан кызына өйләнеп.

Әкият туйда бетә.
Уй чынбарлыкка күчә:
Туең узгач ул яшәү —
Җәфа күреп, чиләнеп!

Җиде диңгез кичәсе,
Гомер юлын үтәсе,
Утка-суга төшәсе —
Яшәгәнче көйләнеп...

## Алтын алма белән хушлашу

*(Егет сүзе)*

Нәрсә булды? Сине күргән көнне
Йөрәккәем кинәт өзелеп төште.
Мондый халәт илаһи бер өндер,
Йә булмаса, артык реаль төшме?

Син кичәнең бер гүзәле идең,
Тик елмаеп миңа дәштең бары.
Бөтерелеп без биегән чакта
Көнләштеләр егет асыллары.

Бу төш белән өн арасы иде,
Чынбарлыкта булмас андый халәт.
Фәрештәләр килеп, колагыма
Пышылдады кебек: «Ярат, ярат!»

Яраттыммы? Әллә инде язмыш
Сынадымы безне көлә-көлә?
Утлар сүнгәч,
дәртләр сүрелә төшкәч,
Аерылырга язган икән менә.

Араларда гади генә киртә:
Мин туганмын бары синнән соңрак.
Барыр юлны бергә итәр өчен
Безнең ара ерак икән, ерак...

Аклый алмам синең өметләрне,
Мин, күрәсең, әле сары томшык.
Минем белән булмый
тормыш корып,
Биеп кенә була очып-очып.

Синең кебек мин дә газапланам,
Алдый алмыйм ләкин хыялларны.

Теге кичә... шундый ымсындырды,
Өметеңә канат куялмады.

Тиңнәреңне табуыңны теләп,
Башлап үзем синнән китеп барам.
Мин әлегә ачы, яшел бөре...
Бәхетле бул, йә хуш, алтын алмам...

## Бәллүр касә

Озайтмакчы булып төшләремне,
Күзләремне ачмыйм, сине күрсәм.
Сине күргән төшне, юратмыйча,
Күңелемдә генә саклап йөртәм.

Бар тылсымлы сүнәр, сүрелер, дип,
Телгә алмыйм якты төшләремне.
Белмисең шул өндә синнән качып,
Төшләремдә өзелеп көткәнемне.

Күзем йомсам, синең шәүләң килә,
Бәгыремне парә-парә телеп.
Саксыз тиеп, уалтудан куркам,
Буш хыялым — бәллүр касә кебек.

## Моңсу табыш

— Вакытлыча бу хис, үтәр,—
дидем,
Тыштан сине шулай юаттым.
Эчтән яндым, ә син кабатладың:
— Мин югалттым сине,
югалттым!..

Керфек какмый август төне үтте,
Өскә яуды йолдыз яңгыры,
Бөрлегәннәр тамды өзелеп-өзелеп,
Сабакларның сыңгач сабыры.

— Мин югалттым сине,
мин югалттым...
Сискәндердең нигә җанымны?
Томырылып чапкан бу гомердә
Очрашырга мизгел табылды!

Күзләреңдә — август моңсулыгы,
Калырсыңмы шулай исемдә?
Мин язмышка рәхмәт укыйм әле
Табыштырган бер кич өчен дә...

## Аерыласы килми, дисең...

Күз алдымда — күз яшьләрең,
Йомшаклыкмы ир-ат өчен?
Искән җилдәй исте вакыт,

Аерыласы килми, дисең.

Сүзләр түгел, күзләр генә,
Җырлар гына калды истә.
Иренеңнән үрелеп үпте
Якты йолдыз айлы кичтә.

— Киттек-киттек,— дип үртәде
Тәгәрмәчләр җанга тиеп.
Үзгәрмәслек кануннар бар —
Саубуллаштык башны иеп.

Сине үпкән йолдыздан да,
Китеп барам, көнли-көнли.
Тәкъдир безгә ниләр язган?
Аерыласы килми, килми!

## Син азат миннән

*(Җыр)*

Ике учак арасында
Айкалу — нинди газап!
Шуны аңлап, мин бүгеннән
Коткарам сине үземнән —
Син азат миннән, азат!

Кыйнама бүтән җаныңны,
Миңа бурычлы санап.
Бүләк итәм шаулы язны,
Бәхетле ит тик бер ярны —
Син азат миннән, азат!

Уттан утка ташланмыйча,
Бердәнбереңне ярат.
Учак кебек мин сүнәрмен,
Юклыгыңа да күнәрмен —
Син азат миннән, азат!

Хисләремне чайпалдырма
Киткәндә — күзгә карап.
Күздән яшьләр тамуы бар,
Тагын китми калуың бар...
Син азат миннән, азат!

## Сездә һәм бездә

Сезнең якта күкләр аяз иде,
Бездә кояш — болыт арасында.
Тик ул көннәр кире кайтмас инде,
Ялварыплар кабат чакырсаң да.

Сездә көннәр җырлы-моңлы иде,
Ап-ак иде урман тирә-якта.
Бездә көннәр сүрән һәм гадәти,
Соры дивар тора безнең сакта.

Сездә тәүлек шундый озын иде,—
Йокламыйча үткәргәнгә төнне.
Ә мин монда кичтән
ятып йоклыйм,
Төшләремдә күрергә дип сине.

Сездә тагын... Сездә —
син бар идең!
Ә биредә — хәтеремдә бары...
Сезнең якның яман ягы да бар —
Син бит анда башка кеше яры.

## Телефонлы хыял

Чылтырагандыр телефон,
Көткәндер эндәшкәнне,
Калтырагандыр туктаусыз
Мин чыгып киткән мәлне.

Чыккан чагым булгандыр шул,
Телефонның теле юк.
Белсәң иде, синнән хәбәр
Көтмәгән бер көнем юк.

Эзлисеңдер кебек мине,
Телефонны ардырып.
Тик кисешми вакыт кына...
Уза йөрәк яндырып.

Кайтарырдай булам сине,
Тыным белән суырып...
Ниһаять... әллә... телефон?!
Төште җаным убылып —
син түгел...

## Һәр икенең берсе...

— Һәр икенең берсе шигырь яза,
Шигырь белән дөнья туп-тулы.
Эч пошырып, каләм тоткан булып,
Син сырлама шигырь, һич югы!

— Һәр икенең берсе шигырь яза,
Шигырьченең сайдыр акылы:
Күпме вакыт шигыренә китә —
Җитди эшләр көткән аркылы!

— Һәр икенең берсе шигырь яза,
Шуның белән яулый игътибар.
Шигырьләре илгә чыгармаса,
Чүп тә түгел үзе, ихтимал!..

— Һәр икенең берсе
шигырь яза,—
Дип үртиләр колак төбемдә.
Һәр икенең берсе...
язсын,

язсын! —
Белеп торам ансын үзем дә.

Илем-көнем, уем-хыялларым
Мәшәкатьләр белән туп-тулы.
Таянычым булган шигырьләрдән
Көнләмәгез мине, һич югы.

## Апрель кары

Ятып ауныйсымы
апрель карларына?
Апрель карларыдай
әллә каралырга?
Кар сулары кебек
язгы җиргә сеңеп,
Умырзая булып кабат яралырга?

Менә нинди хыял,
менә нинди ярсу!
Кучкыл карны ябынып,
җәйрәп ята басу...
Орлык төшәр көнне көтәсеме озак,
Кайчан кузгалыр, дип,
елгаларда ташу?

«Кайчан яфрак ярам?» —
ди каенда бөре.
Кояш нурларында
бүрткән инде үзе...
Ә син, имеш, шулчак,
күзләреңә китеп,
Ямансулап йөре, еламсырап йөре.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аунар идем, диеп,
апрель карларында...
Юләр хыяллар
бер тиеш таралырга.
Бөре сыман бүрткән
хисләреңне тыеп,
Бик акыллы кеше булып
саналырга.

Менә нинди хыял!
Апрель кары эри...
Ә күзләргә бер дә,
бер дә йокы керми!
Шытып чыгачагын умырзая булып
Апрель кары әле
төшендә дә күрми...

## Җыр эзләп

Җыр эзләп килдем Себергә,
Кайтып барам җыр табып.
Ләкин Себер, салкын Себер
Күңелемне калды алып.

Аңлашылмаган аһәңнәр
Ияреп кайта җанга:
Йоклап яткан йөрәгемне
Уятып, ишек кага.

Дөньямны күмеп илһамга,
Кыңгырау булып чыңлый.
Җыр табып кайтам Себердән,
Җаным һаман җыр сорый.

## Шигърият

Шигърият — чибәр кыз, диләр,
Фәрештәгә тиңлиләр.
Лира тотып, канат җилпеп,
Очкан чагын сөйлиләр.

Сөйлиләр ир-атлар гына,
Сурәтлиләр ир-атлар.
Тагын әле күпме шагыйрь
Шул хыялны кабатлар.

Үзләре шуңа ышаныр...
Гаепләмик, бигайбә.
Шигърият дигән могҗиза
Ир затыннан шулай да.

Ир затының иң дәртлесе,
Серлесе һәм көнчесе,
Сөйгәне өчен көрәштә
Мәкерлесе, үчлесе!

Мәхәббәтен бүлешкәнне
Кичерми шигъри иркә:
Сөеклесен — шагыйрәне —
Йә ялгыз, йә тол итә.

И кызыкай, шигърияткә
Багышласаң үзеңне,
Гап-гади җир бәхетеннән
Өметеңне өз инде.

Шигърият — көнчел...

## Шигъри чәчәк

*Нәҗибә Сафинага*

Ак миләүшә...
Миңа — шагыйрәдән
Бүләк иде туган көнемә.
Алсу яраннарга иптәш бүген
Шул чәчәкләр тәрәз төбемдә.

Миләүшәләр, серле миләүшәләр
Чәчәк ата кыш та, язын да.
Бүлмәм эчен гөлем нурландырса,

Төннәр буе шигырь языла.

Миләүшәләр үрчи, бүлгәлим дә,
Шагыйрьләргә үзем таратам.
Аларга да шигъри гөлләремнең
Илһам нурын алып баралсам...

Мин ышанам:
Күңел нурларыбыз
Зур яктылык булып тоташыр —
Юлындагы чүпне, керне юып,
Язгы ташу сыман бер ташыр!

Ак миләүшә — гади чәчәк түгел,
Юл сабучы җаннан җаннарга.
Насыйп булсын
шигъри туганлыкны
Ак чәчәкләр аша барларга.

## Адашларым

*Фирүзә Җамалетдинова һәм*
*Фәйрүзә Исмәгыйловага*

Төрле елда, төрле җирдә
Күкләр безне тергезгән дә,
Тиңләгән исем кушканда
Бәхет ташы фирүзәгә.

Шундый кыю исем белән
Җиңел эшме гомер итү?
Бәхет нуры сибәр өчен,
Йөрәгеңне күмер итү?

Үзебезгә шул бәхеттән
Күпме тигән, адашларым?
Анык кына беләбезме
Шул турыда, җандашларым?

Шигърияттә юлдашларым,
Исемдәме серләребез?
Яшьләребез төрле-төрле
Һәм яшәгән җирләребез.

Гомер юлы — сынау гына.
Таш яуса да безнең башка,
Ялтырыйбыз хыянәтсез
Тутыкмыйча — асылташ ла!

Бәхет ташы фирүзәгә
Тиңләп, күкләр исем биргән.
Өлешебез — шигырьдәшлек,
Мондый бәхет кемгә тигән?

# Мәңгелек өн

## Мин сугышта булдым...

Мин сугышта йөрдем әткәй белән,
Әткәй белән җиңү яулаштым.
Волхов сазлыкларын
кичеп чыктым,
Камалышта калып, адаштым.

Әсирлекнең тойдым ачыларын,
Юкса каян миндә мондый моң?
Шул хакларда китап укысам да,
Шул турыда кино карасам да,
Җаным белән әрнеп елыймын.

Әткәй белән әсирлектән качтым,
Исән кайттым мин дә сугыштан.
«Мин исән!» дип әткәй сөенгәнгә,
Мин тормышны сөйдем тумыштан.

Сугыш беткәч, Сталиннар киткәч,
Мин туганмын җиргә, мин дәвам —
Әнкәйсез дә, әткәйсез дә күптән,
Ничә үлгән, ничә яралган!

Мин сугышта йөрдем әткәй белән,
Күрәсезме, әле мин исән!
Тынычлыкка җыр-мәдхия әйтеп,
Язгы җилләр булып мин исәм.

## Кемнәр ышаныр?

«Мәскәү ышанмый
күз яшьләренә».
Кем әйтте икән моны беренче?
Җансыз, йөрәксез Мәскәү каласы,
Мәскәү каласы — робот тимерче.

Сукканы ләкин тимер түгелдер,
Сандалдан чәчри кан-яшьләр генә.
«Йолдызлар оча!» — диеп алдаша,
Мәскәү ышанмый күз яшьләренә!

Йолдызлар чөеп күз буа Мәскәү,
Бизәкләр уя бетон-ташына...
Мәскәү өстендә кан-яшь болыты
Түгелер икән кемнәр башына?

Тетрәнеп тора карап бар гавам
Тимер Мәскәүнең холыксыз көчен:
Ничек кайтарыр тәкъдир үзенә
Дәрьядай түккән кан-яшьләр үчен?

Шашынып-ярсып сандалны төя —
Ышана шулай гел яшәренә.

...Мәскәү дә бер көн
кан-яшьләр түгәр,
Кемнәр ышаныр күз яшьләренә?

## Кадерсезлек

Дөнья буйлап җәяү китеп барам,—
Хәерлегә... әллә хәерсезгә?
Дөнья тулы кеше арасында
Әверелеп була кадерсезгә.

Дөньясы да кадерсез бит аның,
Җаннарыбыз мең йозакка бикле.
Сабыр төбендәге алтын белән
Юлга чыксак... җитәр кая тикле?

Кая җитсен? Андый гына алтын
Күптән үтте кадерсезлек чиген.
Бөкрәйтәбез билне — күтәргәндә
Дөньябызның шул кирәксез йөген.

Безнең шушы бөкре гәүдәбезне
Турайтырмы әллә кабер генә?
Урам буйлап уйлар уйлап барам,—
Хәерсезгә, әллә хәерлегә.

Урам буйлап җәяү барышларым,
Дөнья тулы япа-ялгыз кеше.
Ауды берсе — кадерсезлек йөген
Күтәралмый кинәт чалкан төште.

«Ярдәм кирәк, ярдәм!» — дия-дия,
Әрле-бирле халык йөгереште.
Һәрберсенең бер кадерсез булып
Яшәвеме исләренә төште?

Дөнья тулы япа-ялгыз кеше,
Җаннарыбыз мең йозакка бикле...
Авар өчен кемгә чират хәзер?
Баралырбыз тагын кая тикле?

Сабыр төбендәге алтыныбыз —
Рухи байлык дигән зур хәзинә —
Кая кадәр алып барыр безне
Һәм аударыр икән кайсы җирдә?

Заман калыбына сыялмаган
Кадерсезләреңә бирче көчең,
Йа бер Ходам! Үз дөньябыз йөген
Кабергәчә армый илтер өчен.

## Казаным

Иделем, Казаным —
Шатлыгым, газабым.
Дулкындай тирбәлер,
Йолдыздай янарым.

Яшьлегем сукмагы,
Гомерем юлыдыр,
Моңнардан яралган
Кызымдыр, улымдыр.

Казаным, Иделем,
Тиңдәше юк илем,
Хыялны чын иткән
Җирләрем син минем.

Казаным, Иделем,
Синдәдер күңелем.
Өметле иртәгәм,
Кадерле бүгенем!

## Проблема юк!

Үзем татар, хатыным чуаш,
Кызны бирдек урыска.
Телем, динем, милләтем, дип,
Баш катырмыйбыз юкка.

Шундый хозур, проблема юк,
Гаиләбез — заманча.
Миллилек төшенчәсеннән
Биек безнең каланча.

Каланчабыз биек икән,
Офыклар да арырак,
«Милләт» дигән кысалардан
Китәрбез әле ерак.

Оныгыбыз үсә хәзер
Барыбызны уздырып:
Лондонда яшәргә тели
Инглиз кызы булып.

Киләчәк буын хакына
Туган телне оныттык,
Яшәсен катнаш гаилә,
Интернациональ дуслык!

Тик нигәдер кайчагында
Өзелеп китә үзәк —
Әнкәм телендә үзара
Бер сөйләшергә теләп.

Ул теләкне корбан итәм,
Онықларга яраса.
Ник булмаска современный?
Проблема юк лабаса!

## Песиле сәгать

Күрше әбинең өй диварында
Песиле сәгать эленеп тора:
Минутлар саный келт тә келт итеп,
Песи күзләре йөренеп тора.

Песиле сәгать, сине күрергә
Йөгереп керәм күршегә көн дә.
Анда да монда күзләр йөренә,
Вакыт агышы туктамый бер дә.

Песиле сәгать, песиле сәгать!
Вакыт үтүе күңелле сиңа.
Мут күзең уйный,
синме — сәгатькә,
Сәгать телеме сиңа буйсына?

Нарасый чагым, бик кызык миңа.
Хуҗа әбигә — Җәмиләттәйгә
Сораулар биреп, йөдәтәм генә:
— Герләре нигә, телләре нигә?

Нәрсә дигәндер, онтылган инде.
Песиле сәгать калган исемдә.
Ялт-йолт уйнатып шаян күзләрен,
Әле дә йөри, йөри төшемдә.

Авылга кайтсам, күршегә керәм,
Күкеле сәгать хәзер диварда:
— Күк-күк, күк-күк,— ди,—
гомер үтте,—ди,
Кызык түгел шул инде миңа да...

## Уен кызык

Үзебез дә зур түгелләр,
Елгабыз да сап-сай инеш.
Яр читенә «өй салабыз»
Суга кереп баскан килеш.

— Кызыл балчык идән булыр,
Түшәк ясыйк аксыл ләмнән.
Өстәл итик менә бусын,
Кирәк тагын чиләк, ләгән...

Уен рәхәт, уен кызык —
Күп бит әле кирәк-ярак.
Барысын да әвәләгәч,
Сокланышып тордык карап.

Бары да бар, нәрсә тагын?
Кызык түгел хәзер безгә:
— Әниләр дә көтәләрдер,
Кайтыйк инде, кызлар, өйгә!

Әле генә өйгә кайттык,
Кайчан гына канат ярдык?
Очып төрле тарафларга,
Үзебез дә өйләр салдык.

Төрле-төрле ояларда
Эшләр бетми, нидер җитми.
Беребез дә, туйдык, диеп,
Үз дөньясын ташлап китми.

Көннәр түгел, еллар үтте,
Шул уеннан булмый узып.
Тормыш гаҗәп уен икән —
Үзе кыен, үзе кызык.

## Гомер

Чыклы үләннәргә беренче кат
Тәпи басып йөгереп киткәндә,
Эссе көндә тирләп-пешеп уйнап,
Үзәк өзелеп тамак кипкәндә,
Чишмә суы — татлы ширбәт,
Яшәү үзе — татлы ширбәт,
Учларыңнан эчеп була,
Бәллүр савыт нигә кирәк?

Яшьлегеңдә яшерен генә сөеп,
Йөрәгеңне ялкын ялмаса,
Яраларың әрнеп сызлаганда,
Дәваларлык чараң калмаса,
Мәхәббәтең — әче шәраб,
Яшәү үзе — әче шәраб,
Йотып җибәр дару итеп,
Савытына торма карап.

Шәраб кайгысымы уйлы башта,
Гомер юлы шундый
мәшәкатьле...
Әллә агу, әллә дару кирәк
Ачкан чакта ачы хакыйкатьне:
Гомер юлы — мәңге яну,
Яшәү — агу, яшәү — дару
(Савытлары — мөлдерәмә!)
Эчкән саен исән калу,
Эчкән саен исән калу!

## Ялтырау

«Туган җир»,— дип сыгынганнар
Туган җирен ташлап китә.
«Милләтем»,— дип сөйләнгәннәр
Милләтенә хыянәт итә.

Эшкә биреп күңелләрен,
Тып-тын гына йөргәннәре —
Туган җире, милләтенең
Энҗеләре, мәрҗәннәре.

Ялтыравык уенчыклар
Камаштыра күзне ныграк.
Чын энҗеләр кабырчыкта,
Чын энҗеләр тыйнаграк.

## Яшәү яме

Кайчагында дөрләп кабынабыз,
Кайчакларда пыскып сүнәбез.
Адәм җаны сөйми торгынлыкны —
Яшибез дә шуңа күрә без.

Гомер буе нидер көтәбез без,
Нидер эзләп алга барабыз.
Өмет зурдан: бәхет нурын сирпеп,
Кабатланмас йолдыз янадыр.

Язлар килде тагын, күкләр биек,
Без табасы йолдыз — югары!
Өметләрнең канатланган чагы...
Тик кунарга урын юк әле...

## Беренче дәрес

— «Татарин» дип үртәделәр мине
Дус малайлар бүген бакчада, —
Улым шулай серен уртаклаша,
Күзләреннән мөлдерәп яшь тама.

— «Татарин» дип?
Сөрт яшеңне, улым,
Шуның өчен елап торалармы?
Бүтән бер дә үртәмәслек итеп,
Гаҗәпләндер үзең син аларны:

«Әйе шул, мин татар, шуңа күрә
Кечкенәдән өстен, диген, сездән,
Сез нибары русча сөйләшәсез,
Мин тумыштан ике телне беләм.

Йә, кайсыгыз бәхәсләшә, диген,
Ике телдә мине җиңә ала?»...
Зиһененә шуны гына салам,
Башка сүзләр артык әле аңа.

Башка сүзләр артык, үсә-үсә,
Ул тагын да күбрәк белер әле,
Татар булып туганына җиргә
Горурланып, сөенеп йөрер әле.

Ә хәзергә улым, үзен яклап,
Шул дәресне саллы җавап итәр.
Дуслары да «татарин» дип аны
Үрти алмас инде моннан битәр.

***

Дөньясы болганчык, болганчык...
Уйларны җыябыз таратып:
Кичереп яшәүче без генә,
Башкалар — гаепле һәрвакыт!

«Мин хаклы!» дигән бер хаксызлык
Торадыр җаннарны каралтып.
Безне дә кичергән, аңлаган
Дусларны югалттык, тараттык.

«Үзебез гаепле!» — диик бер!
Горурлык югыйсә кемдә юк?

Сөйләшер кешеләр бардыр ул,
Аңлаучы кешеләр бер дә юк.

«Мин хаклы!» дигән вак бәхәстә
Бүтәнчә ярышмыйк, ярыш юк.
Югалган табылса яңадан —
Шуннан да кадерле табыш юк!

## Мин-мин дигән берәүгә

«Мин» дисең, «мин» дисең
һаман да,
Син нәрсә телисең шулай да?
Башкалар башларын исенме,
Торсынмы гел синең уңайга?

Карасаң, халәтең кызганыч,
Һәр кеше үзенә — бердәнбер.
Бу җирдә никадәр халык бар —
Һәммәсе торадыр «мин»нән гел.

«Мин» дигән татлы сүз һәр телдә
Яңгырый ешрак барыннан —
Һәркемнең җанына тумыштан
Үзенең дөньясы салынган.

Ә синең бердәнбер «мин»еңә
Шулкадәр дөнья ник баш исен?
Үзеңнең читләргә — «син»нәргә
Бар әле хөрмәтләп карыйсың.

## Кызганыч сабак

Яшь чагында иллә чая идең,
Нинди эш тә килде кулыңнан.
Гөлләр коеп куя белә идең
Һәр нәрсәдән, бары-югыннан.

Яшь чагыңда иллә чая идең,
Көлә идең башка кешедән.
Кыяфәте, холкы, ялгышыннан,
Барып чыгалмаган эшеннән.

Ә үзеңнең бөтен ягың килгән,
Дүрт саның да тигез, гүзәлсең.
Бу дөньяга шатлык җыярга дип,
Уңыш урырга дип килгәнсең.

Көлә-көлә сизми калдың бугай
Чөйлеккәнен тормыш арбаңның.
Көтмәгәндә бише белән кайткан
Кемнәргәдер аяк чалганың.

Тик, кызганыч,
яшь чакларың үткән,
Башлап булмый барын яңадан.

Кулларыннан гөлләр коя белгән
Яңа яшьләр инде яралган.

Кызганам да сине, уйланам да,
Ярдәм итәргә дә юк чарам.
Һич югында, яңа чая яшьләр
Синнән көлмәс диеп ышанам.

## Ни дияргә?

Чиләк тулы шакшы суны
Аудардылар минем өскә.
Әнчек этләр чинап өрде
Шул шакшыга тавыш өстәп.

Ыгы-зыгы һушны алды,
Колакларга тулды ташып.
Чүп-чар тавыш, гауга белән
Диваналар булды башым.

Чәчрәде дә йөзләремә,
Ятып калды дегет сыман.
Су түккәндә күтәрелгән
Кара тузан, кара тузан...

Танымыйча ташлап китте
Дус дип йөргән күпме кеше.
Куырылып килдем үзем,
Тәнем түгел, җаным өшеп.

Әй-йа, дөнья, чайкаласың —
Кайт әле бер урыныңа!
Тынгылыклар бир син миңа,
Мөмкинлек бир юынырга!

Йөрәк кенә әрнер инде
Үткәннәргә кагылганда.
Тик дусларга ни дияргә,
Кабат мине таныганда?

## Хәтер

Хәтер, хәтер, бигрәк озын да син,
Хәтер, хәтер, кайчак кыска да.
Гомерләрем синең кысаңда ла,
Сәгатьләрем синең кысаңда.

Әкият кебек ерак гасырларны
Бүгенгедәй күреп хәтерлим.
Баскыч-баскыч елларымны санап,
Үткәннәрдә янып яшим мин.

Хәтер, хәтер,

бигрәк кыска да син —
Кичәгеләр хәтта онтыла.
Караңгылык канатлары белән
Зиһенемдә кояш тотыла...

Көннәремне көннәр күмгән саен,
Син, хәтерем, кыска гомерле.
Истә тотсам бөтен ваклыкларны,
Болай көлеп яшәр идемме?
Рәхмәт сиңа, хәтер...

## Шаукым

Әй-йа, халкым,
сиңа — һәрбер шаукым
Мәңгелектән килгән канун кебек.
«Югары»дан төшсә
бер-бер фәрман —
Әҗәлләрдән саклар дару кебек.

Фәрман булды мәчет салырга да:
Гөнаһларны йолыр чамалар бар.
Бер-бер артлы мәчет,
мәчет калка,
Авыл саен айлы манаралар.

Әй-йа, халкым,
гөнаһларың — ташкын!
Ташкыныңда ташлар арта тора.
Бу кадәрен уйлар чамалар юк,
Ярлыканыр! — Мәчет сакта тора.

Дөнья җитеш, дөнья түп-түгәрәк!
Тыныч кына мөмкин үләргә дә.
...Күзгә күренмәгән Иблис бии
Мәчетләрдән төшкән күләгәдә...

## Ул көнне...

Ул көнне без —
җим биргәнне көтеп,
Авызын ачкан кош баласы гүя.
Ул көнне без —
яңа гашыйк булган
Сөйгәннәрнең күз карасы гүя.

Ул көнне без — бакчаларга йөргән
Иң самими сабыйларга охшап,
Иңнән кагып үткәннәрнең йөген,
Борчу-гамьнән кинәт кенә бушап,

Тезелешеп утырабыз залда —
Мөкиббәнбез хуплау-мактауларга:
Без нинди шәп, матур,
акыллылар...
Һәм котлаулар
сары майдыр җанга.

Ул серле көн — 8 нче Март булыр,
Безнең җайны ирләр җайлар анда.
Елга бер дә җитә: без, хатын-кыз,

Вәкаләтле шамакайлар анда.

## Идиллия

Безнең йортның подъездында
Әнкә пескәй яши күптән.
Кайдан килгән, кем песие,
Яши монда, дип, нилектән?
Кызыксынмый беркем бездә
Һәм пескәйгә әйтми сүз дә.

Бер тартмага мамык җәеп,
«Фатир биргән» аңа кемдер.
Ә ишекләр ачылганда,
Песи күзе мөлдер-мөлдер:
Ашарына кем китерә —
Рәхмәт дияр шул кешегә.

Безнең йортның подъездында
Кырык фатир — кырык хуҗа:
Пескәебез савытында
Һәрвакытта ризык була.
Менә нинди идиллия!
Рәхмәт яусын безнең өйгә.

Тик урамга чыксаң, яман:
Гел кыргыйлык хөкем сөрә.
Безнең кебек үк кешеләр
Бер-беренә эттәй өрә.
...Әйе, кемнең сабыры юк,
Песи кадәр кадере юк.

## Балалык

Нинди хурлык:
алдадылар мине тагын
Һәм саттылар каһкаһәләп
көлә-көлә.
Мин ташбака Тортилладай
зирәк идем,
Сукыр бер тиен икән юкса
минем бәя!

Могҗизалар кырын эзләп
йөргәнем юк,
Бакыр күмеп,
алтын көтеп ятам мәллә?
Һәркем җирдә ихластыр,
дип ышанам да,
Алданамын хисләремдә
меңәр кәррә.

Мине саткан бакырчылар
уңыш көтә:
Бер сыгылып еласын хет
шушы юләр!
Ә мин менә — Буратино,
агач курчак!

Таммый яшем рәнҗесәм дә.
Чынлап әгәр.

Нинди хурлык:
алдадылар мине кабат,
Агач тәнем сиздермичә калтырана.
Күрәсең, мин — әле һаман
бала-чага:
Охшаш булгач Буратино,
Тортиллага.

## Вакыт машинасы

Гел кайтара вакыт машинасы
Еракларда калган көемә:
Анда минем әткәй-әнкәй исән,
Бер кайгысыз анда йөрелә.

Каен утын яна чытыр-чытыр,
Тәбикмәкләр пешә ак мичтә.
Күрше-күлән хәл белергә керә
Рәхәт, җылы безгә бу кичтә.

Ялгышамы вакыт машинасы?
Мин китәргә никтер ашкынам.
Әткәй, әнкәй, җылы мичләр кала...
Нindидер юл мине чакыра.

Кая китәм? Нигә китәм? Китәм...
Ерагая еллар арасы.
Алып китә вакыт машинасы,
Калыр өчен юктыр чарасы.

Сеңеп калган һәрбер күзәнәккә —
Чишмә кебек тибә шул көем.
«Вакыт машинасы, тик беразга
Шул чагыма алып кайт», — димен.

Һәм кайтамын,
йөгерә-атлый кайтам,
Каршы ала шундый бүгенем:
Сусынымны басар көйләрем дә,
Пакь чишмәм дә... инде юк минем.

## Ике фәлсәфә

Яшь кешенең фәлсәфәсе гаҗәп:
Бәхет эзләр офыклардан ары.
Сүзсез генә яшен коеп торыр
Бакча артындагы тупыллары.

Агачларга күзе төшәме соң?
Алда шатлык — тупыллардан олы!
Офыкларга китеп күмелгәч тә,
Ишетелер әле дәртле җыры...

Карт кешенең фәлсәфәсе башка:
Туган якка юлы, туган якка.

Моңаешып калган тупыллары
Ничә еллар буе шунда тарта.

Туган яктан күңел бизәме соң?
Җырлары да моңлы —
сагынганга.
Мөлдерәшеп күз яшьләре тама,
Тупылларга килеп кагылганда...

## Күчә комнар...

Ишәлтауның инде яртысы юк,
Бульдозерлар һаман кимерә.
Шул тавымның ком бөртеге итеп,
Җилпеп атты язмыш мине дә.

Комнарда — ком,
үләннәрдә — үлән...
Ул тыгызлык күптән югалган.
Үз тавыма кайтып ятар идем,
Үз оямда инде булалмам.

Ашый бара заман бульдозеры
Балачакның текә тауларын.
Насыйп булган менә кичерергә
Тауларның да иңрәп ауганын.

Чит якларда минем үз тавым юк,
Мин — адашкан бер ком бөртеге.
Әллә еллар, әллә җилләр шулай,
Әллә язмыш уйнап бөтерде...

Күпме таулар тагын ишелде?
Күпме комнар... минем шикелле?

## Улым Мисырдан кайткач

Чит җирләрдә гөлләр үсә
Бездәгедән үзгә.
Оазислар — җәннәт сыман
Иксез-чиксез чүлдә.

Кызыл диңгез дулкыннары
Сарылалар тезгә:
— Яшермәгез күңелдәген,
Рәхәт монда сезгә!

Безнең якта көз җилләре
Сызгырадыр инде.
Коелып төшкән яфракларны
Туздырадыр инде.

Ә биредә ел әйләнә
Җәйдән тора көннәр.
Кызлар гына салкын сүзле:
— Харам, харам, — диләр.

Рәхәт монда, яшермибез,
Тик өч кенә көнгә.
Ә аннары тарта өйгә,
Үзебезнең көзгә.

Сагындыра сөйгәннәрнең
Елмаюлы йөзе.
Әниләрнең: «Исән йөр»,— дип
Әйтеп калган сүзе.

Ризыклары экзотик та...
Ашлар тәмле — бездә.
— Сау бул, диңгез, килербез бер
Тик өч кенә көнгә.

## Соңгы кар

Яр өстендә ап-ак булып,
Алмагачлар чәчәк ата.
Ак куяндай йомылып кына,
Яр куенында карлар ята.

Алмагачлар чәчәк ата
Баштанаяк нурда коенып.
...«Сакла безне»,— дип ялвара
Соңгы карлар, ярга сыенып.

Наздан эреп, гөрләвеккә
Әверелүдән куркулары...
Соңгы чиктә, җәйгә чыккач,
Челтерәп агар кар сулары.

Яздан, наздан, яратудан
Мөмкинме соң качып калу?
Илаһи мәл — кар-бозлардан
Ялкынланып сулар агу...

## Шәп без!

*Абыем Ринатка*

Безнең якта Шәбез дигән
инешләр күп —
«Шәп без!» дигән төшенчәне
аңлаткандыр.
Бу тормыштан
шатлык табып яши белү —
Шәбезләре челтерәп аккан
шул яктандыр.

«Шәп без!» —
диеп горурланып яшибез лә,
Йөрәкләрдән әрнеп-сыкрап
кан тамса да.
Шәбез сыман челтерәп
эзгә төшәбез гел —
Ташу дулап,

боз катламын мең ярса да.

Әйе, шәп без!
Бу дөньяга килү бәхете,
Рәхмәт әле, тигән безнең өлешкә дә.
Ни эзләсә, кеше шуны таба, диләр —
Сөенә белик чәчкә төшкән
көмешкә дә.

Сөенә белик,
ямьнәр табыйк бу яшәүдән —
Язмыш бирер көмешен дә,
алтынын да.
Насыйп булсын гомер буе
дус-дошманга
Чын күңелдән: «Шәп без!» —
диеп мактанырга!

## Мәңгелек өн

«Минем кадәр беркем сөелмәгән,
Минем кадәр беркем сөймәгән!..» —
Бер-берсенә пышылдыйлар парлар,
Тын-битараф тора бар галәм.

Аланнарның ак чәчәктә чагы,
Ак өметтә чагы язларның.
Үзгәртергә хәтта сәләтле чак
Язмышларның күктә язганын.

«Безнең белән бәхетледер бу җир,
Без булганга дөнья түгәрәк!» —
Шул сүзләрне тыңлап уянды да
Ай болыттан төште тәгәрәп.

Йолдызларның балкып янган чагы,
Серле чагы айлы төннәрнең.
Йөгерек җилләр тыңлый
салмакланып,
Чишмәләрнең челтерәп көлгәнен.

Шул дөньяга багып ник соң берәү
«Гөлҗамал»ны көйләп моңая?
«Авыр җан сөйгәннәрнең
булмавы»,— ди...
Булган чаклары кая соң,
сөйгән чаклары кая?

Айлар, еллар алышына тора,
Мәңгелек өн бары тынмаган:
«Минем кебек беркем сөелмәгән,
Миндәй җаннар әле тумаган!..»

## Кичке уен

Карашыбыз узмый офыклардан,
Иртәге көн әле билгесез.
«Алын алырсызмы,
гөленме?» — дип,

Каршыбызда биеп йөрисез.

«Алларын да,
гөлләрен дә»,— диеп,
Җырлап кына җавап бирәбез.
Яшь чакларда бар да матур, кызык,
Тукталмыйча уйнап-көләбез.

Зәңгәр төннәр, йолдыз җемелдәтеп,
Ал таңнарга кадәр озата.
Көннәр инде безгә гамәлләрне
Һәм юлларны ялгыз сайлата.

Ай-йолдызлы якты хыялларын
Алып китә бирәү яшьлектән.
Кара булып туа гамәлләре
Кемнәрнеңдер. Нидән, нилектән?

Аллы-гөлле түгел тормыш юлы,
Ни өчендер аклы-каралы.
Көтә күрмә кара күңел белән
Офыгыңда йолдыз янганны.

Кичке уен исләремә төшсә,
Хәйран калып торам язмышка.
Киләчәкнең үз җавабы әзер
Яхшылыкка, яман, ялгышка.

«Алларынмы,
гөлләренме?» — диеп,
Ул чакта соң кемнәр көлеште?..
Баксаң, язмыш үзе бүлә икән
Өлешләргә тигән көмешне.

## Их, дөньясы!

Әллә дөнья артык әйбәт,
Әллә үзем начар мин:
Ил күзенә чыккан саен,
Үз өнемә качам мин.

Әллә тормыш — тоташ бәйрәм,
Әллә халкымы — сәрхуш:
Куеннарда шешә булса,
Башларында кәләпүш.

Әллә данга ирештекме,
Әллә төштек мескенгә?
— Син дә шуңа ireш, диләр,
Юкны-барны тикшермә!

Әллә, дим соң, төкеримме?
Аһ, коега — төкерек!
Суы кирәк булмагае...
Кая барма — исерек!

## Кызыма

Бәйлисең, киясең, сүтәсең,
Яңадан бәйлисең башкача —
Баштарак сайлаган үрнәгең
Буеңа-сыныңа ятмаса.

Түземең түкәнмәү серенә
Төшенә алмыйча баш ватам.
Тик гап-гади эшләрдә кайвакыт
Сабырың сынуга шаккатам.

Тормышның юллары бормалы —
Бер — шома,
бер — баткак, сикәлтә.
Сынатмый узарсың — бары тик
Түзәргә сабырың җитәлсә.

Сүтәсең, бәйлисең — синең эш,
Үзеңә киясе барыбер.
Тик юллар сайлаган чагында,
Мең уйла һәм уйла тагы бер.

## Иң бөек сер

Бу дөнья үзгәрә, яңара,
Үзгәртә вакытлар агышы.
Җилләргә, суларга ияреп,
Китә дә онтыла барысы.

Тик мәңге үзгәрми бөек сер —
Икәүнең тоташ бер җан чагы.
Бу халәт, бу изге бергәлек
Суларга ияреп акмады.

Җилләр дә иярте китмәде,
Мәңгелек мәхәббәт сакланды:
Иң нечкә, иң нәфис хатынның
Арыслан йөрәкле чаклары.

Туачак бәбие хакына
Матур да, батыр да булганы...
Үзгәрми сер йөрткән ананың
Йөзендә чагылган нурлары.

Һәм мәңге үзгәрми бөек сер —
Бәбинең беренче авазы,
Яңа җан тудырган ананың
Шатлыкка әйләнгән газабы.

## Сәер халәт

«Әни» дигән сүзне ишетүгә,
Ирексездән карыйм борылып,
Шул сүз белән эндәшүче бала
Минекедер төсле тоелып.

Белеп торам юкса минем балам
Бу минутта монда түгелен.

«Әни» дигән сүзне ишетәм дә,
Урыныннан куба күңелем.

Бер баланың бер сүзеннән кинәт
Сискәнүем, бәлки, гаҗәптер.
Ләкин мине һәрбер әни аңлар —
Үзләрендә шундый халәттер.

## Алданасы килә

Мамык сыман күперепләр тора —
Һаваларда болыт нинди йомшак!
Шул мамыкка чумып уйнар идек,
Кеше түгел, фәрештәләр булсак.

Кай арада болыт карала да,
Энҗе яңгыр ява шыбыр-шыбыр.
Әнә инде кояш чыгып килә,
Җәй җылысы торыр әле, торыр.

Буш хыяллар җилгә генә оча,
Яшьлек аны белә инде, белә...
Мираж булса булсын, ак болытта
Әле һаман очасылар килә.

## Бәйрәм

Чәчләремне буяп, бөдрәләттем,
Яңа күлмәк кидем өстемә.
Иренемә шат елмаю элдем —
Дус-ишләрем күрсен өченгә.

Көзгеләргә багып, сөрмә тарттым,
Күзләремдә чаткы балкыды.
Мин үземне курчак иттем бүген,
Уйны-гамьне сызып аркылы.

Бусагадан атлап чыктым шулай,
Күргәннәрнең теле бәйләнде.
Бер танышым, иҗекләргә салып:
— Әллә,— диде,—
берәр бәй-рәм-ме?

Әйе, бәйрәм! Минем күңелемдә!
Үз кәефем үзем күтәрдем:
Чәчәк итеп тойдым үз-үземне
Тормыш дигән олы түтәлнең.

Кыңгыраудай җиргә иелсәм дә,
Көнбагыштай көнгә баксам да,
Чиге булыр гомер җәйләремнең,
Көзләр керер яшел бакчама.

Әлегә мин җәйләремдә яшим
Һәм беләмен аның китәсен.
Шуңа күрә, яшәвемне данлап,
Килде бүген бәйрәм итәсем.

## Дустымның туган көне

Ел саен яшьне саныйбыз
Туган көннәр җитсә,
Мәктәп, класс һәм парталар
Исебезгә төшсә.

Мәктәп еллары озын да,
Калган гомер кыска.
Математикабыз шулай
Алдашамы юкса?

Бер үк елны ничә төрле
Була икән санап?
Тиздән илле, дип офтандың
Календарьга карап.

Иптәш кызым, ромашкалар
Җыеп килдем менә.
Яшь чакларга кайтып килик
Тик бер көнгә генә.

Ромашкалар хыялдай ак,
Тик уртасы сары.
Илле яшь юк әле безгә,
Кырык тугыз бары!

## Алкаларым сыңар-сыңар

*(Җыр)*

Алкаларым сыңар-сыңар,
Йә югала, йә сына.
Сыңар-сыңар алкаларым
Үз парларын юксына.

Челтерәми инде күптән
Колагымда тамчылар.
Карыймын да алып куям —
Алкам гел сыңар-сыңар.

Өстәлемдә ничә алка
Моңая ялгыз гына.
Һәркайсына пары кирәк
Таң булып кабынырга.

Уйнамаган инде күптән
Колагымда таң нуры.
Карыймын да алып куям —
Сыңар алкалар моңлы.

Алкаларның берсенә дә
Тиң түгел башка сыңар.
Шулар сыман парсыз гына
Минем дә гомер узар.

Биемәсләр инде бүтән
Колагымда алкалар.

Карыймын да алып куям,
Һәркайсы сыңар-сыңар.

## Күбәләк

Бу дөньяның хозурлыгы
Акылыннан яздыра.
Аллы-гөлле чәчәкләре
Күзләрен чагылдыра.

Иксез-чиксез зәңгәрлеккә
Күтәрелергә теләп,
Чәчәк сыман канатларын
Җилпеп карый күбәләк.

Ни үкенеч: дөнья ямен
Тәрәзә чикләп тора.
Ватып кара, дигән сыман,
Аны үчекләп тора.

Килер әле кем дә булса —
Бер ачылыр тәрәзә.
Ул арада кояш байый,
Төнге күктә ай йөзә.

Алларында тәрәзә лә
Очам дигән мәлендә...
...Кайчагында үзебез дә
Шул күбәләк хәлендә.

## Җиде җил чатында

Җиде юл чатында...
Җиде җил чатында
Җил искән тарафтан
Ут-уклар атыла.

Җәяләр киереп,
Җиде ук атканда,
Җиде ят бер уйда:
— Һәлакәт — башкага!

Җил исә төрлечә —
Мәшрикътан, мәгъриптән...
Ут-уклар кемнәрне
Аударыр кинәттән?

Йөгерәм, өлгерәм
Җиде юл чатына!
Җиде ук сызгыра
Алдымда, артымда...

Минем җан, кош булып,
Күкләргә ашканда
Җиде як исән-сау!
...Һәлакәт — башкага...

## Төшенкелектә

Кабер белән кадер сүзе
Аваздаш, дисәм, нигә? —
Баксаң, кабергә кергәндә,
Күпләргә кадер килә.

Соңлап килгән андый кадер
Кирәк микән кешегә?
Күфер сүз сөйлимме юкса? —
Рәхмәт шунсы өчен дә.

Гомерендә кадер күреп
Яшәүчеләр күп, димә.
Халык — диңгез!
Шул диңгездә
Ялгыз кеше чүп кенә.

Кадер күрердәй булмасаң
Кабереңә ингәндә,
Бу дөньяда яшәвең һәм
Үлүеңнән ни мәгънә?

## Тамчылар

Җилләр исә, сулар ага,
Еллар үтә, гасырлар...
Чиксез диңгез киңлегендә
Без бары тик — тамчылар.

Тик шулай да күбекләнеп,
Сикерешеп алабыз:
«Диңгезләр бездән җыела,
Без тарихта калабыз!»

Еллар ага, дулкыннарны
Комлы ярга кагалар.
Тамчыларда өмет зурдан:
«Тарих үзе аралар!»

Нинди тарих? Һәр дулкынның
Тамчылары өр-яңа.
Һәрберебез үз елында,
Үз гасырында кала.

Яңа гасыр дулкыннарның
Яңасын таләп итәр.
Үз тамчылары кирәгер
Ул чакта бездән битәр.

Күпсенә күрмә, дулкыным,
Бүгенең булып калыйм.
Башка тамчыларың кебек
Айкалыйм да чайкалыйм.

## Мин

Кайда ярлы, кайда зарлы,
Кайда моңлы күп була —
Мин шулар янында булам,
Алар белән килешеп була.
*М.Гафури*

Кайда исерек, кайда болтун
Һәм шарлатан күп була —
Мин мескен шунда булырмын,
Минем белән килешеп була.

Аңларга теләп һәркайсын,
Керермен хәлләренә.
Чишелер чама бирермен
Тасмадай телләренә.

Колагымны шәлперәйтеп
Тыңлармын онытылып.
Колач салып йөзәрмен мин,
Сүзләр дулкынын ерып.

Күренермен һичбер эшсез,
Кайгысыз кеше булып.
Колакларым гүләп торыр,
Баш мием шыплап тулып.

Халәтемне берсенә дә
Әйтергә кыя алмам.
Исерекләр һәм болтуннар
Килер дә килер һаман...

## «Син нишлисең әле?..»

— Син нишлисең әле? —
Нинди сүз бу?
Каян килеп сукты башыма?
Бер җавапсыз аңгы-миңге торам.
«Агып барам язгы ташуда!»

— Син нишлисең әле?
— Нәрсә диим?
Мин еракта мондый сораудан.
Җаным-тәнем, бар халәтем белән
Үз-үземә кереп югалган.

— Син нишлисең әле? —
Шул сорауга
Көтелә бит әле җавап та.
«Җем-җем иткән йолдызларны
күзләп,
Очып барам космик корабта!»

Тик шулай да,
чынбарлыкка кайтып,
Җәһәт кенә җавап коралмыйм.
Шуңа күрә башкалардан да һич:
— Син нишлисең? —
диеп сорамыйм.

## Мәче йоклый өстәлдә...

Өстәл лампасын кабызсам,
Мәче менә өстәлгә,
Кәгазьләр кыштырдавына
«Мыр-мыр» тавышы өстәлә.

Таралыплар йоклап ята,
Җылы тансык аңа да.
Назга мохтаҗ җан иясе,
Туны барга карама.

Төшләренә әнкәсенең
Иркәләве керәдер.
Кешедән күргән игътибар
Аңа бик кечкенәдер.

Туганнары белән, имеш,
Ятадыр йомарланып,
Арада иң-иң йомшагы,
Кадерлесе саналып.

Лампа астындагы мәче
Әнә шундый төш күрә.
Ара-тирә миңа сөйли,
Йокысын бүлә-бүлә.

Ышанмыйсыз? Минем дә бит
Хыялланыр хакым бар:
Наздан гына торган җаным,
Шагыйрь дигән атым бар...

## Ялкаулык

Тәрәзәдән тәрәзәгә йөрим,
Берьялгызым өйдә калган чакта.
Тынычлыкны яратсам да, никтер
Ияләшә алмыйм ялгызлыкка.

Эштән ияреп кайткан
кәгазьләрне
Читкә куеп, аш пешерер идем,
Тәм-томнарны өстәлемә тезеп,
Гаиләмә чәй эчерер идем.

Кайда шулай озак йөрдегез, дип,
Юри генә битәрлисем килә.
Тәрәзәдән тәрәзәгә йөрим,
Ямь табалмый аптырыймын өйдә.

Менә-менә берсе кайтыр, димен,
Ә кәгазьләр язганымны көтә.
Яннарына якын бармас өчен
Сәбәп кирәк миңа бик тә, бик тә...

## Эштән соң

Кыска курткалы юан хатыннар
Урамнар тулы, урамнар тулы.
Икешәр сумка күтәргәне бар,
Тик берсенең дә буш түгел кулы.

Кыска курткалы юан хатыннар
Капюшон кия яңгыр астында.
Зонтигын ачып тотыр иде дә,
Өченче кулы юк шул ансына.

Эштән кайтышлый базарга кергән,
Кибеткә кергән юл уңаенда...
Йөкләре һаман түбәнгә тарта,
Шуңа күрә дә юанаела.

Озын итәкле зифа яшь кызлар
Кәс-кәс атлыйлар шул ук урамнан.
Кул селтәп эштән кайтучы ирләр
Күзләрен алмый әнә шулардан.

## Йомгак

Бөтереләм орчык булып,
Тәгәрим гүя йомгак.
Язмыш нидер бәйли миннән
Энәгә җебем урап.

Язмыш бәйли, аның саен
Мин кечерәк, кечерәк.
Бәйләгәне — бияләйдер,
Бәлки, оек, йә күлмәк.

Матур итеп бәйләнәме,
Уңым-сулым тигезме?
Нәфис бизәк ясалганмы? —
Кемдер киеп йөрерме?

Кая куяр аны оста,
Сүтелеп беткәч җебем?
...Ә мин никтер йомгак чагым
Онытмауларын телим.

## Вакытым юк чакта

— Утыр инде!
Ашыгасың тагын кая? —
дип сорап,
арган тәнне ымсындырып,
буш эскәмия тора.

## Шәһәрдә яз

Юмарт кояш көлде.
Таш Казанга

шаулап яз килде тагын.
Авыл язын уйлап,
мин базардан
тал песиләре алдым.

## Болында

Ромашкаларның уртасы
Кояш нурларын эчкән.
Чукларына — күктә йөзгән
Ак болыт төсе күчкән.

Күбәләкләр, быж-быжаннар
Киләләр дә куналар.
«Сине генә сөям»,— диеп,
Пышылдаган булалар.

## Элеккечә калам

Язмышымнан канәгать мин.
Юмарт минем язмыш:
Шатлыгым да, кайгым да күп,
Дөреслек бар, ялгыш...

Шашкын хисләр һаман исән,
Һаман чыга ерып,
Куе сагыш дулкыннарын,
Акылымнан узып.

Сабыйларча башсызлыгым
Элеккечә һаман.
Ярый әле, егылсам да,
Үзем булып калам.

Ярый әле, ялгышымны
Күреп көлә беләм,
Үз-үземне, юләр, диеп,
Тетеп сүгә беләм.

Тик шулай да, ярый әле,
Һаман дөрлим, янам.
Киртәләрне көл итәргә
Элеккечә калам.

## Феникс

Янам-янам да кабат яралам
Көлдән яралган Феникс кебек.
Күтәрелмәкче булам һавага,
Каурыйларыма ярамны төреп.

«И юләр кошкай, әкият бит ул
Кабат яралу, терелү кабат»,—
Кемдер шулай дип эндәште бугай
Мин узган юллар-елларны санап.

Искә төшермә, дәшмә, ят тавыш,
Бу хакта инде мин беләм күптән.
Аһ, мин нинди карт,
борынгы, диеп,
 Япь-яшь көннәрем,
гомерем үткән.

Янам-янам да кабат яралам,
Ә бер көн килер — ярала алмам?
— Гомерләр узган,
картайганмын,— дип,
Бүтән беркайчан инде зарланмам?

Исән чагында гөнаһ түгелдер
Көлдән яралу Феникс сыман.
Яраларымны канатым каплар,
Күз яшьләремне яңгырлар юар...

## Тузганак.
## Җәй бусагасында

Тузганактан такыя үрдем
Җәйләргә кергән чакта.
Тузганаклар очар-китәр,
Ниләр үсәр алмашка?

Ромашкалар, кыңгыраулар,
Күкчәчәкләр... дисеңме?
Истә тоту мөмкин түгел
Йөзәрләгән исемне.

Ә тузганак — җәебезнең
Иң беренче чәчәге,
Күзебезгә шатлык булып,
Нур булып күчәчәге.

Алдыгызда җәй озын, дип,
Ымсындырып торганы,
Түрләргә зурлап озаткач,
Ак болыттай тузганы.

## Җәй кошы

Уразай болыннарында
Чәчәк кенә печәннәр —
Өмә булыр, җыярлар, дип,
Без килгәнне көткәннәр.

Агыйдел суы юганга,
Иң ямьле болыннардыр...
Өмәгә килми калганнар
Эчләрен уганнардыр

Җәйнең матур мизгелләрен
Күрмәгәнгә үкенеп...
Әмма йомгак —
җәй йомгагы —

Тәгәрәгән сүтелеп.

Килгәннәрдән дә үткән ул,
Үткән килмәгәннән дә —
Печән җыю рәхәтләрен
Сизгән, сизмәгәннән дә.

Үтте инде, иреннәрдә
Калды җиләк тәмнәре.
Яшьлек чоры бер генә шул,
Басты тормыш гамьнәре.

Әмма рәхмәт ул чакларга —
Ямьнәре калды җанда.
Җәй кошы мин — күңелемдә
Шул болыннарым барда.

## Кычыткан аралары

Сандугач оясы таптык
Кычыткан арасыннан.
«Бизә күрмәсен анасы
Бер оя баласыннан», —

Дип, читкәрәк китеп бардык,
Монда килмәгән сыман,
Печән чабып, печән җыеп,
Кем дә йөрмәгән сыман.

Сандугачлы кычытканлык
Ныгытма — кирмән кебек,
Камыллар тигезлегеннән
Калды күккә үрелеп.

Кычытканнар бишегендә
Тирбәлә сандугачлар.
Ныгыр да нәни канатлар,
Зәңгәр күкне колачлар.

Кимсетеп карый күрмәгез
Кычыткан, дип, нибары.
Бәллүр тәхет анда гүя
Сандугач оялары.

## Югалттык

Сагынмыйм, сагынмыйм,
уйламыйм,
Тик төшкә керәсең нигәдер:
Яшьлектә, җиләкле аланда
Без тагын икебез бергәдер.

— Мин таптым җиләклек!
— Мин дә! — дип,
Очынып, сөенеп йөргән чак.
Син — мине, мин сине сыйлаган,
Гөл-чәчәк җыйган чак бер кочак.

Нигә соң ашыктык, ашыктык?
Күп иде бит әле җиләкләр...
Пырылдап кабынды матаең,
Очардай җилкенде йөрәкләр.

Без киттек, җиләкле аланның
Белмәдек калганын мәңгегә.
Җиләклек таптык та югалттык...
Син дә бит? Ә бәлки, мин генә?..

## Хәйран

Ак күлмәгем, яшел дүмгәләкле...
Сабантуйга әнкәй бүләк итте.
Бөтерелеп очтым күбәләктәй,
Кемдер күрде, кемдер күрми үтте.

Ул күлмәгем артык гади иде,
Чәчләрем дә гади — ике толым.
— Әйдә, әнкәй,
бергә барыйк, — дигәч,
— Мин көтәрмен, — диде, —
өйдә, кызым.

Ничек инде өйдә утырырсың,
Гөрләп торса аллы-гөлле мәйдан?
Сый әзерләп, коймак коеп безгә,
Өйдә калган әнкәемә — хәйран.

Хәйран, хәйран...
Үзем дә бит хәзер
Озатам да өйдә генә калам —
Улым китә, кызым... кыска чәчен
Иңбашына сүтеп кенә салган.

Күбәләктәй очып кына бара,
Кемдер күрә, кемдер күрми уза.
Өйдә калам. Тәрәзәдән карап.
Рәшә кебек кенә гомер сыза...

## Җәйге төн

Җәйге төннәр
бигрәк кыска инде:
Керфек каккан ара — яктыра,
Ян бакчада сандугачлар сайрый,
Әкият илләренә чакыра:

— Йоклап ятма таңда,
йоклап ятма,
Җәй үтә бит, күрми каласың!
Иртә торсаң гына табып була
Җәйне озайтулар чарасын.

— И сандугач,
җырчы кошым минем,

Хак булсачы өзелеп сайравың.
Төне буе сине тыңлап чыктым,
Җәйләремдә кала алмадым.

И сандугач, фәлсәфәче кошым,
Йөрәгемдә син — ел әйләнә.
Сайрый күңел,
сайрый сиңа кушылып,
Җәйгә күзләр, кышлар бәйләнә.

Җәйге төннәр
бигрәк кыска инде,
Тагын бер төн
керфек какмый чыктым —
Ян бакчада сайраганын тыңлап
Сандугачның, фәлсәфәче кошның.

## Юкәле Кул

Юкәле Кул суы ага
Кыр-басу уртасыннан.
Төнбоеклары тирбәлә
Уйларга талган сыман.

Юкәле Кул акрын ага,
Көтеп арадыр Шәбез.
Суга йомычка салыйк та,
Узышыйк әле, ягез!

Без сулардан җитезрәк,
Без сулардан дәртлерәк.
Төнбоек боеклыгына
Төшенә алмый йөрәк.

Ак төнбоек — өмет икән,
Сагынмак — сарылары.
...Киткәннән соң ничә кайттым,
Ул якка барылмады.

Узышларда ерак киттек.
Юкәле Кул — тымызык.
Оттыкмы соң? —
Томан аша
Таңнар көлә сызылып.

## Чыллә

Чамасыз кыздыра бу кояш!
Күк йөзе зәп-зәңгәр, ап-аяз.
Бу җәйләр үтүгә, яңадан
Килсәче җәй башы — яңа яз.

Тирбәтсен иде гел көмеш күл
Кояшта кызарган тәннәрне.
Балкысын иде лә күңелдә,
Күзләрдә ел буе җәй яме!

Кызганыч, бары да —
тик мизгел
Күлләрдә уйнаган тамчыдай.
Күзләрнең киләсен искәртеп,
Яшеннәр сызыла камчыдай...

## Юаныч

Җәйләр узды, димәгез,
Күзләр инде, димәгез,
Чәчәкләрем шиңде, диеп,
Башыгызны имәгез.

Аллы-гөлле җәй күңелдә
Кышлар үткәнче яшәр,
Күбәләге итеп безне
Кабат үзенә дәшәр.

## Мираж

Агыйделнең яры текә
Без печән җыйган якта.
Сулары күзгә күренми
Еракка киткән чакта.

Покослары — озын-озын,
Күк гөмбәзе — нык биек.
Кояш кыздыра тәннәрне
Табада коймак кебек.

Адаштыра, саташтыра,
Ахры, көннең кызуы:
Ишетелгән кебек була
Нәрсәдер пошкыруы.

Бер гыйфрит киләме әллә
Болын печәнен ерып?
Катып калабыз берара
Гүя тораташ булып.

Агыйделнең пароходы
Кызыккан бугай безгә:
Болынлыкта печән чаба,
Покослар итеп тезә.

Без болынның түрендә шул,
Су күренми, су ерак.
Коры җирдә — пароход, дип,
Күзәтеп тордык озак.

## Җәйләр узгач

Бу бураннар кайчан тынар, дисең,
Кышкы салкын кайчан сынар,
дисең...
Гомер җебен азлап сүтә-сүтә,

Күңел никтер һаман җәйне көтә.

Йөрәк ярсый җәйләр якынлашса,
Нишләр идең, җәйләр чакырмаса?
Ымсындырып озын кышларыңда
Килер җәең булсын —
ышаныргa.

Килер җәең килә, үтеп китә...
Күңел хәзер ниләр өмет итә?
Сизмичә дә калдың җәйнең ямен,
Кадерлерәк — аны көткән мәлең.

Җан сүрелеп көзләренә,
Җәйдән сагыш күчә күзгә генә:
Җәйге хисләр —
йөрәк ярасы шул,
Көтү белән китү арасы шул.

# Балаларга – әкият

## Мәче бәхете

*Резеда һәм Гүзәлгә*

Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр
Адым саен дөньяда.
Әкият ич, болар миңа
Кагылмас дип уйлама.

Синең кебек иң гадәти
Бер кыз иде Минзада.
Ул күргәнне сөйләп китсәң,
Язылмаслык тузга да.

Тузга язмаган хәлләрнең
Ни икәнен беләсең.
Ул кыз баштан кичергәнне
Төшеңдә дә күрмәссең.

Менә болай: бер көн иртән
Уяна да Минзада:
— Көн дә мәктәпкә барудан
Туйдым, — диеп зарлана.

Мич башында, мыр-мыр килеп,
Мәче йоклап ята, ди.
Шуңа карап көнләшүдән,
Минзада сүз ката, ди:

— Их, миңа да шул мәченең
Бәхетен бирсә Ходай.
Йоклап кына ятар идем,
Интекмәс идем болай.

Көн дә дәрес әзерлисе,
Укыйсы булмас иде.
«Ике»ле алмагаем, дип,
Нервылар тузмас иде...

Мәче шунда киерелеп:
— Ишеттем, ми-яу,— диде.—
Минем язмышны теләсәң,
Хәйләсе болай,— диде.—

Йомарлан да калач кебек,
Мич башына менеп ят.
«Мыр-мыр-мияу,
мыр-мыр-мияу».—
Дип кабатла бер йөз кат.

— Шул гынамы? Мин мәктәптә
Моннан күбрәк сүз ятлыйм,—
Дип, Минзада мич башына
Сикереп менеп ятты.

Тылсым сүзен йөз кат әйткәч,
Әверелде мәчегә...
Менә хәзер мәктәбендә
Эзләсеннәр, көтсеннәр!

Мәче дөньясына күчте.
Монда башка мәшәкать:
Сөт эчә дә тагын йоклый,
Мәче-кызый канәгать.

Бер көнен йоклап үткәрде.
Әмма чиге бар икән.
Дус мәчесе әйтте аңа:
— Әйдә киттек, тор, иркәм!

Мәчеләрнең дә мәктәбе
Була үзенә күрә.
«Тычкан тоту» фәне генә —
Йөз дә җитмеш биш сүрә.

Күршеләрнең ак мәчесе —
Ул Мыраужан исемле —
Койма башыннан йөрергә
Өйрәтер аннан сине.

Эт куганда качу серен
Яхшы белә Песигөл.
Ул һөнәрне белми калсаң,
Йоннарың күп тетелер.

Түземсезләнде Минзада:
— Ярар,— диде,— аңладым.—
Өйрәнермен калганнарын,
Тычкан тота алмамын.

(Тычканнардан курка бит ул.
Үрә тора йоннары.)
Мәчесе дә усал тагын,

Ташламага бармады:

— Гел-гел минем тәлинкәдән
Бушлай ашармын, димсең?
Тычкан тоту — сиңа куйган
Таләпнең беренчесе!

Остаз-мәче Минзаданы
Келәткә алып китте.
Тычкан-күселәр артыннан
Аны гына йөгертте.

Өч тычкан тотты да кызый,
Хәлдән таеп егылды.
Ашамады. Чи ит капса,
Чирләр кебек тоелды.

Дус мәчесе, тамак туйгач,
Кайтып тормады өйгә.
Минзада аның янында
Төн үткәрде ач көйгә.

Песигөл белән Мыраужан
Килделәр иртәгәсен.
Алары болай үткәрде
Үзләренең «дәрес»ен:

Эт оясы түбәсенә
Менделәр өчәүләшеп.
Үртәгән булып Актүшне,
Уйнашып та телләшеп.

Актүш башта ялкау гына
Һау-һаулап өреп куйды.
Песигөл шунда түбәдән
Тәпиен аска сузды.

Тәпиен тора уйнатып
Этнең танау төбендә!
Бу нахалга ничек түзсен —
Актүш дурак түгел лә!

Ярсып чыкты оясыннан,
Сикерде өсләренә.
Шул хут белән баганага
Бәрелде өстәвенә.

Ә песиләр, ай-һай, оста,
Койма башыннан чаба.
Әүкән-тәүкән, әүкән-тәүкән
Чак җитешә Минзада.

Ачуыннан шашкан Актүш
Инде тотты дигәндә,
Тәгәрәп төште коймадан
Тыкрык ягы чирәмгә.

Котылуы шушы икән,

Эт — койманың артында!
...Бүтән көнләшмәс мәчедән,
Кеше итче, йа Хода!

*

Булмас димә, дөнья бит бу,
Теләгәч ихласыннан,
Кабат кеше тормышына
Ничектер кайта алган.

Уф-ф, дигән бер,
аһ-һ, дигән бер,
Ни генә килмәс телгә,
Сүзне үлчәп сөйлә икән,
Чынга әйләнмәс, димә.

Шатлыкларым да җитәрлек,
Түгел мәшәкать кенә.
Үз бәхетем көтә мине,
Кермәм мәченекенә!

## Алтын капка

Әбинең ындыр артында,
Яшелчә бакчасында,
Капка баганасы булып
Ике тупыл утыра.

Кул сузымы булса булыр
Аралары югыйсә —
Ә мин алтын капка күрәм,
Шунда карадым исә.

Алтын канатларын ачып,
Эчкә үтәм капкадан.
Кергән саен яңа дөнья,
Карыйм да хәйран калам.

Ялгыз керү кызык түгел,
Миңа якын дус кирәк.
Тик шунысы: могҗизаны
Күрә алучы сирәк.

Уйлап таптым: ул капкага
Әниемне әйдәдем.
Мине аннан да яхшырак
Аңлаучылар юк әле.

Әниемнең күзенә дә
Алтын капка күренгән:
Әкиятләр иленә без
Атлап чыктык бүгеннән.

Әнием дә, минем кебек,
Бер бәләкәй кыз булды.
Яшьтәшем дә түгел әле,
Сеңелем күк тоелды.

Җитәкләдем дә сеңелне,
Киттем инеш буена.
Чупырдашып уйнау инде
Хәзер минем уемда.

Каз бәбкәләре тезелеп,
Үлән чемченеп йөри.
Уйнарга теләми сеңел,
Әллә чын, әллә юри.

— Югарыга кара әле,
Күктә тилгән оча,— ди.—
Саклап торыйк, бәбкәләрне
Алып китәр юкса,— ди.

Ничек кенә ялынсам да,
Тыңламады ул мине.
Шулай итеп, кичкә кадәр
Бәбкә сакладык инде.

Соң гына кайттык авылга,
Тормадым мин карышып.
Ул арада көтү белән
Маллар кайтты чабышып.

Кечкенә дә төш кенәдер:
— Сыер савыйк,— ди сеңел.
Әби көлеп карап тора,
Карышу мөмкин түгел.

Алмаш-тилмәш эчтек аннан
Үзебез сауган сөтне.
Ул арада әбекәйнең
Бәрәңгесе дә иеште.

Ашадык та, көянтәләп
Су кайтардык чишмәдән.
Сеңел түзә, минем генә
Әле дә сызлый җилкәләр.

Мал-туарны кич йөртергә
Алып чыктык яланга.
Бер уңайдан уйнарга дип
Килгән кызлар-малайлар.

Минем сеңел уйный гына...
Белмим, ничек армаган?
Мин чирәмгә яткан килеш
Йоклаганмын яланда.

Уяндым әни кулында
Алтын капка янында.
Кабатланырмы икән соң,
Бу әкият тагын да?

Мин бик ардым, үсеп кайттым,
Әни яшәргән менә:

— Алтын капка аръягында
Калмадык,— диде,— нигә?

— Телевизор карап кына
Утырыйк әле өйдә.
Аннан тагын барырбыз! — дип,
Вәгъдә бирдем әнигә.

## Сер итеп — сезгә генә

Ни могҗиза, ни тамаша —
Ник дөньяны су баса?
Таш юллардан, бакчалардан...
Юлсыз җирдән дә таша!

Туфлиләргә, чүәкләргә
Челтерәп тула кереп,
Баскычлардан баскычларга
Ага шарлавык кебек.

Язгы ташу ярсый мәллә
Шәһәр урамнарында?
Болай булса, күмеп китәр
Тыр-тыр... трамвайларын да!

«Ава-ри-я»,— дия-дия
Машиналар кычкырта,
Аның саен, зур-зур кабып,
Коры җирне су йота.

Әй кешеләр йөгереште,
Сызганылган җиңнәре...
Тик берсе дә суны ничек
Туктасын белмәде!

Ярсу дулкын кага торгач,
Мәктәпкә җиткән икән.
Әйтерсең лә мәктәбе дә
Шул мәлне көткән икән:

Укучылар ук шикелле
Атылган, ди, ишектән.
Җиде яшьлек Диләрә дә
Су тавышын ишеткән.

Миннән башка моны беркем
Туктата алмас, дигән,
Бу бәланең сәбәпләрен
Ачмый ярамас, дигән.

Безнең өйдә бүген әни
Кер юып калды, дигән,
Кызык өчен машинага
Мин кадак салдым, дигән.

Кер юу машинабызны
Шул кадак тишкән инде.

Тишегеннән ярсый-ярсый
Су агып төшкән инде.

Машинада су кими дип,
Әни һаман өстәгән!
Шаяртмакчы булган идем —
Шәһәребез нишләгән?

Әй кешеләр йөгергәннәр
Диләрәнең өенә.
Әнисе ишек ачкан, ди,
Кер чайкаган көенә.

Кергәннәр дә, ди, кешеләр,
Су кранын япканнар.
Машинаның кадак тишкән
Урыннарын тапканнар.

Ямаганнар, төзәткәннәр
Алып куеп керләрен...
Ышанмыйча торасызмы? —
Хак дөресен сөйләдем.

Диләрә сер итеп кенә
Миңа сөйләгән иде.
Бу турыда башкаларга
Җиткер, димәгән иде.

Кадак тишкән машина күк,
Сер тормый бит миндә дә.
Сезгә генә сөйләдем лә —
Үпкәләмәс Диләрә.

## Сихерче Җәмил

Җәмил кәмит күрсәтә,
Кәмитче булу — уе.
Лагерьдагы малайларны
Шаккатыра җәй буе.

Учларына таяна да
Кул белән атлап йөри.
Чәчәк түтәленә җиткәч,
Егылган була юри.

Баштүбән бауга тотынып,
Таган атынып карый.
Ачыгавыз нәниләрне
Куркытып, бармак яный.

— Мин — сихерче, шүрлектәге
Бер китаптан төштем,— ди,—
Кешеләр танымасынга
Малай булып үстем,— ди.—

Үзем теләгән кадәрле
Малай булып яшим дә,

Сезне урлап, тагын күчәм
Әкиятем эченә.

Ә сез анда, әкияттә,
Минем коллар булырсыз,
Ни әйтсәм дә, буйсынырсыз,
— Баш өсте,— дип торырсыз...

Сихеренә ышаналар,
Шул Җәмилдән шүрлиләр.
Могҗизалар булмый, димә,
НЛОлар йөри лә...

Тик бер малай эчтән генә
Шуны уйлап баш вата:
— НЛОлар йөрсә йөрер,
Сихерчеләр ул башка.

Сихерчеләр җен затыннан,
Куркытыйм,— ди,—
эт белән! —
Җәмил кыланган урынга
Этен ияртеп килгән.

Эттән куркып торамы соң —
Узынган бу Җәмил дә.
Колагыннан тотып тарта.
Нигә тарта? — Әл-ли-лә-ә!

— Әл-ли-лә! — дип котылсачы
Бармак авырткан чакта!
Хет файдасы тияр иде
Бал корты-мазар чакса...

Хактыр инде: эт тешли, ди,
Сихерчене, пәрине.
Җитмәсә, табиб чакырта
Бүлмәсенә — Җәмилне!

Укол кадаган чагында
Түзми Җәмил, кычкыра.
Шифасы тия тиюен:
Сихер көче ычкына.

Ычкына да оча сихер
НЛОларга таба.
Җәмилнең йомшак җирендә
Укол урыны кала.

Уколдан да елап торгач,
Бик тиз үсәлмәс инде.
Әкиятләр китабына
Кабат күчәлмәс инде.

## Эчтәлек

*Н.Сафина.* Талпынудан туган агым ...

**Кар суында – ак каеннар...**

Яз ..........................
Өстенлектә (Шаяру) .............
Унҗидедә .....................
Сак-Сок .......................
Син – әкият ....................
Дулкынланам? ..................
Үтенеч ........................
Сер ..........................
Әллә ни булды миңа .............
Пар чынаяк куйдым... ...........
Миләүшә .....................
Көндәшем .....................
Таң ..........................
Язлар җитсә ....................
Сабантуй .....................
Гипноз .......................
Йолдыз идем ..................
«Үзгәртте мәхәббәт...» ...........
Беренче кар ....................
Мәхәббәтем микән? ...............
Гөлләр сере ....................
Шул гына .....................
Яратам .......................
Оялчан егет ....................
Үзгәрү юк .....................
Таң атканда ....................
Үзе бәлә... ....................
Сихерче ......................
Иске өй ......................
Кайтырсың... .................
Нәсыйхәт *(Шаяру)* ...............
Югыйсә... ....................
Карга бураны ..................
Минсез дә... ...................
Сөенечкә ......................
Бәрәннәр һәм адәмнәр ............
Оптимистик шигырь .............
Егет булмыйк әле ................
Сау булыгыз, китәм... ............
Хикмәт .......................
Ташкалага кем баш кала? ..........
Чәйгә чакыру ..................
Һавасыз... ....................
Исеңдәме? .....................
Син курыкма ..................
Син ..........................

**Бәллүр касә**

Гашыйк ......................
«Сезнең күзләрегез...» ............
Аңларсыңмы? ..................
Яшь аралаш көлү ................
Бәлки... ......................
Йолдыз нуры ..................
Чың .........................
Кара урман ....................
Коръән арасында калган хат ........
Каршылык ....................
Минем исем ...................
Соңгы чакыру ..................
Янмый учак ...................
Күңел генә бушап калды ...........
Яфрак хәлендә .................
Әбиләр чуагы ..................
Баян .........................
Автопортрет (Шаяру) .............
Аккош күле ....................
Яңгырда ......................
Юату ........................

Көз ...........................
Кышкы чишмә ..................
Бәсле теләк .....................
Үкенеч ........................
Су буенда ......................
Тукталыш .....................
Фараз .........................
Син киткәч .....................
Ясалма гөл .....................
Юл догасы .....................
Кем әйткән? ....................
Хуш! ..........................
Тынгылык бир! ..................
«Рәхәт лә ул...» ..................
Туйлар илә уйлар... ..............
Алтын алма белән хушлашу (Егет сүзе)
Бәллүр касә ....................
Моңсу табыш ...................
Аерыласы килми, дисең... ..........
Син азат миннән (Җыр) ............
Сездә һәм бездә ..................
Телефонлы хыял .................
Һәр икенең берсе... ..............
Апрель кары ....................
Җыр эзләп .....................
Шигърият .....................
Шигъри чәчәк ..................
Адашларым ....................

**Мәңгелек өн**

Мин сугышта булдым... ...........
Кемнәр ышаныр? .................
Кадерсезлек ....................
Казаным .......................
Проблема юк! ...................
Песиле сәгать ...................
Уен кызык .....................
Гомер .........................
Ялтырау .......................
Яшәү яме ......................
Беренче дәрес ...................
«Дөньясы болганчык...» ...........
Мин-мин дигән берәүгә ............
Кызганыч сабак .................
Ни дияргә? .....................
Хәтер .........................
Шаукым ......................
Ул көнне... .....................
Идиллия .......................
Балалык .......................
Вакыт машинасы ................
Ике фәлсәфә ....................
Күчә комнар... ..................
Улым Мисырдан кайткач ..........
Соңгы кар ......................
Шәп без! .......................
Мәңгелек өн ....................
Кечке уен ......................
Их, дөньясы! ....................
Кызыма .......................
Иң бөек сер .....................
Сәер халәт .....................
Алданасы килә .................
Бәйрәм ........................
Дустымның туган көне ............
Алкаларым сыңар-сыңар (Җыр) .....
Күбәләк .......................
Җиде җил чатында ..............
Төшенкелектә ...................
Тамчылар .....................
Мин ..........................
«Син нишлисең әле?..» ............
Мәче йоклый өстәлдә... ............
Ялкаулык .....................

Эштән соң .....................
Йомгак ........................
Вакытым юк чакта ..............
Шәһәрдә яз ....................
Болында .......................
Элеккечә калам ................
Феникс .......................
Тузганак. Җәй бусагасында .........
Җәй кошы ....................
Кычыткан аралары ..............
Югалттык .....................
Хәйран ........................
Җәйге төн .....................
Юкәле Кул ....................
Челлә .........................
Юаныч ........................
Мираж ........................
Җәйләр узгач ..................

**Балаларга – әкият**

Мәче бәхете ....................
Алтын капка ..................
Сер итеп – сезгә генә .............
Сихерче Җәмил ................

Литературно-художественное издание

*Муслимова Файруза Асгатовна*

**Апрельский снег**

*Стихи*

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Р.Р.Шәмсетдинов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә
салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия
2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 2.03.2004.
Форматы $70x90^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. Офсет басма. Шартлы басма табагы 6,44 + форз. 0,15.
Шартлы буяу-оттиск 7,32. Нәшер-хисап табагы 5,70 + форз. 0,26. Тиражы 2000 экз. Заказ Э-154.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Бауман ур. 19.
Татарское книжное издательство. 420111, ул.Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/  E-mail:  tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahattм программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.
Оригинал-макет подготовлен с помощью пакета программ Jahattм.

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы
дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.